ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

# 2018/2019 НЧЫ УКУ ЕЛЫНДА ТАТАР ТЕЛЕН ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫН ЧИТ ӘДӘБИЯТ БУЛАРАК УКЫТУНЫҢ АКТУАЛЬ ПРОБЛЕМАЛАРЫ

Казан
2018

ББК 74.268.1 Тат
Т23

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән килешенеп,
Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының
Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә

Ректор, педагогика фәннәре докторы Л.Н. Ногманованың
гомуми редакциясендә

**Рецензентлар:**

**Халиков И.И.,** Милли мәгариф идарәсенең милли мәгариф бүлеге җитәкчесе, филология фәннәре кандидаты

**Җамалетдинова З.И.,** ТР Мәгарифне үстерү институның мәктәпкәчә һәм башлангыч белем бирү кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты

**Төзүчеләр:**

**Шәмсетдинова Р.Р.,** Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, доцент, филология фәннәре кандидаты

**Фәттахова Р.Ф.,** татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты

**Гыйләҗева Л.Г.,** татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты

**Һадиева Г.В.,** татар теле һәм әдәбияты кафедрасы өлкән укытучысы

**Мөхәрләмова Г.Н.,** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать инсититутының өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты

2018/2019 нчы уку елында татар телен дәүләт теле һәм татар әдәбиятын чит әдәбият буларак укытуның актуаль проблемалары / төз.: Р.Р. Шәмсетдинова, Р. Ф. Фәттахова, Л.Г.Гыйләҗева һ.б. — Казан: ТРМҮИ, 2018. — 48 б.

© ТРМҮИ, 2018

## ЭЧТӘЛЕК

Кереш ........................................................................................................ 4

Татар теле һәм әдәбияты укытучысының эшчәнлеген билгели торган норматив документлар ................................................................................. 21

Татар телен дәүләт теле буларак укытуны тәэмин итә торган укыту-методик комплексларга күзәтү ....................................................................... 25

Планлаштырган нәтиҗәләргә ирешү ................................................................ 30

Уку предметларыннан эш программалары төзү буенча методик тәкъдимнәр ........................................................................................................ 34

Дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру буенча методик тәкъдимнәр ................ 36

Тәкъдим ителгән әдәбият исемлеге .................................................................. 45

# КЕРЕШ

Татарстан мәктәпләрендә татар теле рус телендә сөйләшүче балаларга республикабыздагы дәүләт телләренең берсе буларак укытыла. Дәүләт теле буларак татар теле укучыларда сөйләм эшчәнлегенең төп төрләрендә аралашу (коммуникатив) компетенцияләре формалаштыру, телдән һәм язма сөйләм культурасы нигезләрен үзләштерү, укучыларның яшь үзенчәлекләренә туры китереп, аралашуның төрле очракларында татар телен куллану осталыгын арттыру һәм күнекмәләрен булдыру максаты белән укытыла. Татар теле укучыларда көндәлек тормышта сөйләм коммуникациясе, күпмәдәниятле җәмгыятьтә үзара аңлашу мөмкинлеге формалаштырырга тиеш була.

Татар телен дәүләт теле буларак укытуның *максаты* — укучыларның коммуникатив компетенцияләрен формалаштыру, танып белү, гомуми уку күнекмәләрен, сөйләм культурасын үстерү, татар милләтенә, аның тарихи һәм мәдәни хәзинәләренә карата хөрмәт тәрбияләү, укучыларны мәдәниятара диалогка тарту һәм татар телен дәүләт теле буларак өйрәнүгә ихтыяҗ тудыру. Татар теле дәресләре укучыларның фикер йөртү,интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә хезмәт итәргә, аларны татар халкының мәдәнияте һәм милли үзенчәлекләренә якынайтырга, башка халыкларга карата хөрмәт хисе, толерантлык, мәдәниятара аралашу осталыгы кебек универсаль күнекмәләр булдыруга этәргеч ясарга тиеш.

Татар телен дәүләт теле буларак укытуның *бурычлары* булып укучыларның сүз байлыгын арттыру, фикерләү сәләтен үстерү, укучыларның сөйләм һәм язма телен камилләштерү, тел өйрәтүдә сөйләм эшчәнлегенең дүрт төреннән файдалану (ишетеп аңлау, сөйләү (диалог, монолог), уку, язу) күнекмәләре формалаштыру тора.

Татар телен дәүләт теле буларак укытуны аралашучан-эшлекле, информатив (мәгълүматлы), эчтәлекле, кызыклы итү, укучыларда татар теленә кызыксыну уяту мөһим. Бу яктан, телне укытуның аны фән буларак өйрәнүдән — аралашу, шәхси яктан үсү, универсаль уку гамәлләрен үзләштерү чарасы буларак өйрәнүгә таба күчүен билгеләп үтәргә кирәк. Татар телен дәүләт теле буларак укытуны телне чит тел буларак өйрәнү технологияләрен куллануның мөһимлеген аңлап оештырырга кирәк. Укучыларга татар телен өйрәткәндә мәгълүмати-аралашу технологияләреннән файдалануны көчәйтергә һәм киңәйтергә, кирәкле

дидактик материаллар, электрон сүзлекләр, хрестоматиялардән актив файдаланырга киңәш итү мөһим.

Аралашуга өйрәтү технологиясе, ягъни коммуникатив технология Е.И. Пассов, В.П. Кузовлев, В.Б. Царьков һ.б. хезмәтләренә нигезләнә. Бу технологиягә корылган дәресләрдә күнегүләр системасы аралашуга корылган. Е.И. Пассов ике төр күнегүне аерып күрсәтә: шартлы тел күнегүләре һәм тел күнегүләре. Шартлы тел күнегүләре күнекмәләр үстерү максатыннан махсус оештырыла. Бу күнегүләр бер типтагы лексик берәмлекләрнең кабатлануына нигезләнә. Тел күнегүләре аша лексика һәм грамматиканы күпләп өйрәнү мөмкинлеге тормышка ашырыла. Күнегүләр эшләү барышында хаталарны төзәтү эше дә оештырыла. Фонетик хаталарны төзәтү максатыннан һәр дәрестә фонетик күнегүләр планлаштырыла. Татар теленә генә хас булган нинди дә булса аваз алына һәм 1–2 атна дәвамында шул авазны дөрес әйтү өстендә күнегүләр эшләнелә. Ә грамматик хаталарны төзәтүгә барлык укучыларның игътибарын тарту мөһим, ләкин кагыйдәләрне аңлату озакка сузылырга тиеш түгел. Коммуникатив технологиянең өстенлеге укыту процессында сөйләм материалын барлык балаларның да үзләштерә алуы өчен шартлар булдыруда. Коммуниктив технология нигезендә укыту цикллылыкка корылган. Цикл — текстны укып, аның эчтәлеген диалогик, монологик, ягъни мөстәкыйль сөйләм дәрәҗәсенә җиткерү өчен кирәк булган дәресләр саны. Бу сан даими түгел. Ул текстның лингвистик катлаулылыгына, текстның күләменә бәйле. Методик әдәбиятта күрсәтелгәнчә, текстны өйрәнү өч этаптан тора: текст алды, текст белән эшләү этабы, тексттан соңгы этап. Беренче этапта укучылар текстны лингвистик яктан кабул итәргә әзерләнәләр. Дәрес тибы буенча бу дәресләр — лексик күнекмәләр һәм грамматик күнекмәләр формалаштыру дәресләре (ЛКФ , ГКФ ). Бу дәресләрнең эчтәлеге турыдан-туры текст эчтәлеге белән бәйле. Укучылар текстны лингвистик яктан кабул итәргә әзерләнгәч, текстның үзен укуга күчәргә мөмкин. Бу дәрестә текстны уку, текст өстендә эшләү буенча күнегүләр системасы өстенлек итә. Дәрес тибы буенча әлеге дәресләр — лексик-грамматик күнекмәләрне камилләштерү дәресләре (ЛГК , ЛК, ГК), алга таба диалогик-монологик сөйләм үстерү дәресләре оештырыла. Коммуникатив метод лексик берәмлекләрне һәм аларның грамматик формаларын билгеле бер ситуацияләргә бәйләп өйрәтүне таләп итә. Чынбарлыкта кешеләр, аралашу сферасыннан чыгып, бер-берсе белән хәбәрләшәләр һәм моның өчен кирәкле тел берәмлекләреннән файдаланалар. Шуңа күрә дә икенче телне өйрәнгәндә, аралашу ситуацияләренә бәйле

репликаларны истә калдыру телне гамәли үзләштерүне җиңеләйтә һәм аның нәтиҗәлелеген арттыра. (Р.Б.Камаева).

В.Ф. Шаталов технологиясе укытуны камилләштерүдә схемалар һәм терәк билгеләргә таянуга нигезләнгән. Эшчәнлекне оештырганда берничә принципны исәпкә алу мөһим:

— материалны күп тапкырлар кабатлау аша үзләштерүне;
— материалны эре блокларга берләштереп өйрәнүне;
— терәк материалга таянуны;
— һәр укучыга шәхси якын килүне;
— гуманлылыкны (һәр бала талантлы!);
— мәҗбүр итмичә укытуны;
— конфликтсыз укыту, һәр баланың уңышын билгеләп, бәяләп баруны, үсеш юлларын алдан күрсәтеп эшләүне;
— укыту һәм тәрбия берлеген.

Уку процессын оештырыу һәм идарә итүнең нәтиҗәлелегенә нигезләнгән педагогик технологияләрдән С.И. Лысенкова технологиясе. Педагог-новатор төрле интеллектуаль мөмкинлекләре булган укучылар белән өстәмә дәресләрсез, ата-аналар ярдәменнән башка эшләү методикасын төзи. Дәрестә авыр темаларны өйрәнгәндә, башта — көчле, аннары — уртача, ахырдан исә йомшаграк укучылар эшли. Шулай итеп, белем бирү процессында, көчләреннән килгәнчә, барлык балалар да катнаша. Бу методиканың төп нигезләмәләре:

— эзлеклелек, өйрәнелә торган материалны бирүгә системалы якын килү;
— сәләтле укучының көчсезрәгенә ярдәм итүе;
— балага шәхси якын килү;
— хаталарны кисәтү;
— сыйныфта үзара ярдәмләшү мохите, уңайлы шартлар тудыру;
— уку материалының һәр укучыга көче җитәрлек итеп бирелүе.

Терәк схемалар, укытучы материалны аңлаткан вакытта, балалар күз алдында ук туа һәм схема, таблица, рәсем, карточкалар рәвешендә тәкъдим ителә. Укытучы белән алып барылган эшчәнлеккә укучы аңлатма биреп бара: («уйлыйм», «әйтәм», «язам»). Билгеле булганча, рус сыйныфларында укучыларның әзерлек дәрәҗәләре төрлечә була. Шул сәбәпле, татар теле дәресләрендә С.Н. Лысенкова технологиясен файдалану (бигрәк тә башлангыч сыйныфларда) өйрәнелә торган телдә сөйләм эшчәнлегенең белем һәм күнекмәләрен үзләштерүне яңа дәрәҗәгә күтәрүне тәэмин итә. Материалның схемаларга салынып бирелүе күрү хәтере яхшырак булган

укучылар өчен бигрәк тә уңайлы санала, шулай ук башкаларга да билгеле бер теманы, тел күренешен схема рәвешендә системалы истә калдырырга ярдәм итә.

Рус төркемнәрендә татар телен укытуда коммуникатив технологияне куллану укучыларда түбәндәге коммуникатив компетенцияләрне формалаштырырга мөмкинлек бирәчәк:

— татар телендә төрле максатларда һәм ситуацияләрдә аралаша белү күнекмәләре барлыкка килү;
— аралашу өчен продуктив лексик минимумны үзләштерү;
— фонетика, лексикология, грамматикага караган материалны төрле аралашу ситуацияләрендә дөрес куллана белү;
— диалогик сөйләм күнекмәләре барлыкка килү;
— аерым темалар буенча монологик сөйләм күнекмәләре формалашу;
— татар телендә текстларны укып аңлау, укыган буенча фикер әйтә белү.

Татар теленә өйрәтү, нинди генә технология кулланылса да, татар мәдәниятенә, тарихына хөрмәтле караш формалаштыру; табигать, халык, культура, дин төрлелеген берләштергән дөньяга толерантлык формалаштыру белән берлектә барырга тиеш.

Рус мәктәпләрендә коммуникатив юнәлештә татар телен укыту процессы түбәндәге ***принципларны*** истә тотып тормышка ашырыла:

1. *Актив сөйләм принцибы, ягъни телне актив аралашу аркылы өйрәтү.* Бу принцип дәреснең гамәли характерын билгели. Телне грамматикадан аралашуга таба түгел, ә аралашудан грамматик нормаларны камилләштерүгә таба өйрәнү максатка ярашлы. Димәк, дәрестә актив аралашуга корылган күнегүләр үткәрелә, бу күнегүләр аша салмак, сиздермичә, ләкин максатчан, «дозалап» телнең грамматик нормаларын үзләштерү, лексикасын өйрәнү һәм актив сөйләмдә грамоталы итеп куллану тормышка ашырыла. Сөйләмдә кулланылмый торган фразалар дәрестә өйрәнелми.

Атаклы психологлар А.Н. Леонтьев, П.Я. Гальперин фикеренчә, белемнәрне үзләштерү аларны нинди дә булса эшчәнлектә куллану аша бара. Сөйләмгә өйрәтү процессы башта аерым сүзләр, грамматик категорияләр өйрәнеп, аннан шулар нигезендә сөйләм оештыру аша барса, бу бик кызыксыз, нәтиҗәсез юл булыр иде. Коммуникатив технология нигезендә башта балаларның яшь үзенчәлегенә карап, аларның аралашу сфералары, аралашу ситуацияләре ачыклана, аннан соң ул сфераларда сөйләшүне оештыра алырлык лингвистик материал сайлана.

2. *Функциональлек принцибы.* Сөйләм эшчәнлегендә өч юнәлеш тыгыз бәйләнештә: лексик, грамматик, фонетик. Аралашуга корылган эшлекле биремнәрдә төрле тел берәмлекләре үзләштерелә: укучы сорау бирә, фикерне раслый, инкарь итә, шикләнә, риза була, әңгәмәдәшен нindидер эшкә чакыра һ.б. Һәрбер очракта билгеле бер грамматик форманы үзләштерү һәм ныгыту тормышка ашырыла. Грамматик материал авыр, озын кагыйдәләр биреп ятлату формасында түгел, ә лексик-грамматик төзелмәләр формасында тәкъдим ителә. Аларны үзләштерү сөйләм ситуацияләре нигезендә оештырыла. Лексик-грамматик формалар җиңелрәк формадан башлап, әкренләп катлауландырыла.

3. *Ситуативлык принцибы* — укыту материалын сайлаганда һәм укыту процессын оештырганда, укучыларның яшь үзенчәлекләрен һәм кызыксынуларын искә алып, проблемалы ситуацияләрне коммуникатив хәл итүгә максималь игътибар бирелә. Укучылар, төрле рольләргә кереп, ситуацияле уеннарда катнашалар. Ситуатив биремнәрне дөрес формалаштыруга аеруча игътибарлы булырга кирәк, мәсәлән, «Балалар мәйданчыгында», «Касса янында», «Аптекада» дип кенә ситуатцияне атап үтү генә ситуация барлыкка китерми, аралашу ихтыяҗы барлыкка килми, сөйләм күнекмәләре формалашмый. Бары реаль ситуация эчендә реаль рольләргә бүленеп кенә укучыларда аралашу ихтыяҗы барлыкка китереп була.

Телне аралашу ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, укучылар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен шунда ук тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм тел өйрәнү процессының мотивлашкан булуын тәэмин ителә.

4. *Яңалык принцибы*. Бу дәреснең төрле компонентларында чагылыш таба: сөйләм ситуацияләрнең яңалыгы, ягъни аралашу предметының/темасының, сөйләшү проблемасының, партнерларның, сөйләшү шартларының алмашынуы/дәрес саен үзгәреп торуы, дәресне төрлечә оештыру (төрен, формасын), укыту алымнарын алмаштыру.

5. Һәр баланың сөйләм күнекмәләре төрлечә формалаша. Моңа төрле факторлар йогынты ясый: психофизиологик, социаль, укучыларның яшәү тирәлеге, кызыксыну сфералары, эшчәнлек төрләре һ.б. Болар барысы да шулай ук коммуникатив сәләткә йогынты ясый. Шуңа күрә *уку процессын индивидуальләштерү принцибы* — укыту процессын укучыларның теләк-омтылышларын, индивидуаль-психологик үзенчәлекләрен исәпкә алып оештыруны күздә тота.

Димәк, коммуникатив компетенцияләрне уңышлы үстерү өчен укытучы һәр укучыга шәхси якын килеп кенә ирешә ала:

— укучының индивидуаль һәм яшь үзенчәлекләрен истә тоту;

— укучының уңай сыйфатларын алга чыгару;

— укучының шәхси уңышларын ныгыту, күрсәтү.

Белем бирү өлкәсендә укучыларның коммуникатив үсешен тәэмин итү балаларның психологиясен һәм шәхесе үсү законнарын һәм механизмнарын белеп эш иткәндә генә нәтиҗәле була. Телгә өйрәтү дәресләрендә төрле кызыклы сөйләм ситуацияләрен оештыру, шуларга нигезләнеп, укучыларның аралашу осталыгын үстерүгә игътибарны арттыру, укучыларга төрле социаль рольләр башкару, кирәкле репликаларны дөрес куллану өчен сөйләм эшчәнлеген оештыру мөһим. Сөйләм ситуациясен оештырганда, коммуникатив биремнәрдән, сюжетлы рәсемнәрдән, мультфильмнар, фильмнардан алынган өзекләрдән, презентацияләрдән, коммуникатив уеннардан файдалану яхшы нәтиҗәләр бирә. Бу эш төрләре, билгеле инде, балаларның кызыксыну даирәләреннән, яшь үзенчәлекләреннән, сәләтләреннән чыгып сайланырга тиеш. Аралашуга корылган дәресләрдә коммуникатив уеннар оештыру аеруча отышлы. Уйнаганда, балалар үзләренә якын булган сөйләм ситуацияләрен җанландыра, проблемалы ситуацияләр барлыкка китерә һәм шуларны чишүгә ирешә алалар. Коммуникатив уеннарның тәрбияви әһәмияте дә зур: укучыларда игътибарлылык, ярдәмчеллек, үз-үзләренә ышанучанлык, үз уңышларына шатлану хисләре тәрбияләнә.

Бүгенге көндә рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен тәкъдим ителгән УМК лар, нигездә, коммуникатив технология таләпләренә нигезләнеп төзелгән. Укытучылар коммуникатив технологияләрнең нигезләрен яхшы үзләштереп, уңышлы гына дәрес үрнәкләре дә күрсәтәләр.

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Мәгарифне үстерү институты рус телле балаларга татар телен укытуны камилләштерүгә юнәлдерелгән ике *проект өстендә эшләде.* Татар телен укытуга сәгатьләр саны кыскарган шартларда, телне өйрәтү элеге проектларда каралган юнәлештә алып барылса, нәтиҗәлерәк булыр дип уйлыйбыз.

*Беренчесе — методик сертификация. Бу проект Валерия Николаевна Мещерякованың авторлык программасына нигезләнеп алып барылды, ул коммуникатив һәм уен технологияләренә нигезләнгән система булып тора.*

В.Н. Мещерякова авторлык программасының төп максатларының берсе — мәктәптә татар телен предмет буларак өйрәнүгә карата киеренкелекне киметү, уңай булмаган фикер-мөнәсәбәтләрне юкка чыгару, йомшарту.

Икенче максат — рус телле балаларны татарча сөйләшергә өйрәтү, сөйләмгә чыгару, икенче төрле әйткәндә, коммуникатив компетенцияләрне булдыру. Ул татар телен уку-укытуда хәл ителмәгән үзәк проблемаларның берсе — рус төркемнәрендә татар телен өйрәнүгә каралган сәгатьләр санының гамәли нәтиҗәләр белән туры килмәвенә бәйле. Чыннан да, татар телен өйрәнүгә 11 ел вакыт бирелә, сәгатьләр саны канәгатьләнерлек. Әмма 11 ел мәктәптә татар телен өйрәнгән рус телле яшьләрнең бик азы гына татарча сөйләшә-аңлаша аладыр. Тестларны уңышлы тапшырсалар да, сөйләм күнекмәләре шактый түбән дәрәҗәдә кала. Тырышлары, акыллылары татарча укый, сүзлек ярдәмендә тәрҗемә итә ала, диалог яки билгеле бер темага монолог төзи, ләкин араларында татарча һич кенә тартынмыйча иркен сөйләшә торганнары күп түгел. Дәресләрдә сөйләм барьеры формалашканлыктан һәм сөйләм күнекмәләре тиешле дәрәҗәдә үстерелмәгәнлектән, татар телендә сөйләшү мөмкинлеге булган очракта да алар аннан файдаланмый. Тел өйрәнүдәге кыенлыклар укучыларның мотивациясен тагын да киметә, уңышсызлык ситуациясен китереп чыгара. Телнең грамматик нигезләрен өйрәнү, балаларның логик фикерләве калыплашкач, максатка ярашлы. Телне (сөйләмне түгел) никадәр генә яхшы белсәң дә, ул, даими рәвештә гамәли куллануга кертелмәсә, бер авыр йөккә әверелә.

**Методик сертификация проектында катнашучы укытучыларның фикерләре:** “Билгеле, сөйләм формалаштыруны күздә тоткан технологияләр аз түгел. Әмма ни сәбәпледер, нәтиҗәләргә күз салсак, бүгенге көндә алар бик аз санлы укытучылар тарафыннан даими, системалы рәвештә кулланылышка кертелә.

В.Н. Мещерякованың авторлык системасы дәресләрнең эчтәлеген дә, формасын да, оештыру рәвешен дә тулысынча, бөтен нечкәлекләрен исәпкә алып яктырта һәм алда әйтелгән мәсьәләрне хәл итәргә мөмкинлек бирә. Без моңа үзебез шул система белән эшли башлагач төшендек. Беренчедән, татар теле дәресләре 1 нче сыйныф укучыларының иң яраткан, көтеп алган дәресләренә әверелде, моны әти-әниләр дә бик хуплады. Икенчедән, бер ел нәтиҗәләренә караганда, әлеге технология буенча эшләгән укытучыларның балалары дәрестә билгеле бер күләмдә татарча аңлый һәм аңлаша ала.

Система психологик киеренкелек тудырмыйча, димәк, тел барьерын булдырмыйча укыту мөмкинлеге концепциясенә корылган һәм эзлекле рәвештә тыңлап аңлау — сөйләү — уку — язу — тел анализы аша сөйләм

күнекмәләрен үстерүне күздә тота. Монда балаларның яшь һәм психофизиологик үзенчәлекләре бик нык исәпкә алынган. Ул да булса:

1) тел өйрәнүдә табигыйлеккә таяну;
2) ишетеп аңлау (аудирование);
3) психологик рәхәтлек;
4) тел мохитенә чумдыру;
5) чит телне өйрәнүне баланың шәхси үсешенә, иҗади сәләтен ачуга юнәлтү.

Нәрсә ул табигыйлеккә таяну? Ул — балаларның 9–10 яшькә кадәр предметларны, төрле образларны инстинктив рәвештә кабул итү, истә калдыру сәләтенә таяну. Бала үз туган телендә кечкенәдән үк ничек сөйләшергә өйрәнсә, шул рәвешле чит телне дә отып ала. Балаларның баш миендә, үзләштерелергә тиешле калыпларны кабат-кабат тыңлау, ягъни аудирование аша, өйрәнелә торган телнең төп структурасы-образы тудырыла. Ни рәвешле? 9 яшькә хәтле сөйләм механизмы сыгылмалы, шуңа күрә табигый, ягъни кат-кат ишетү аша, тел образын тудыру юлын сайларга кирәк. Ятлату, мәҗбүр итү, бер телдән икенче телгә турыдан-туры тәрҗемә итүгә дә юл куелмый. Кечкенә баланы, мәҗбүр итмичә, ничек сөйләмгә чыгарырга? Әлбәттә, уен аша. Чөнки уен — бу яшьтәге баланың төп эшчәнлеге ул.

Дәрестә уңайлы, рәхәт атмосфера тудыру бик мөһим. Дәрескә балалар теләп йөрергә тиеш. Мин моны кайчандыр бер хыял итеп кенә күз алдыма китерә идем. Әмма ул чынга ашты. Балаларны мавыктыру кирәк. Дәрестә киеренкелек булмасын өчен, тоташ төрле-төрле уеннарны алыштырып торабыз, сөйләм тән, кул, йөз хәрәкәтләре белән бергә аралаштырып барыла. Төп дәрес тибы — ул сөйләм телен үстерү дәресе, ә төп дәрес формасы — уен. Ул уку дәресләре һәм кереш дәрес, контроль дәресләр белән аралашып барыла Уку дәресләрендә без җырлыйбыз, келәмгә түгәрәкләнеп утырып, лото, домино уйныйбыз; кереш дәрестә аудиодәрес тыңлыйбыз, кайбер уеннарны уйнап карыйбыз; контроль дәрестә укучылар эш дәфтәрендә эшли: рәсем ясыйлар, рәсемнәрне төрле буяуларга буйыйлар, бераз язалар. Эшләрне папкага җыеп, уку елы ахырында әти-әниләре белән бергә балалар китапчыклар тегә.

Укытучының ялгыш җавап биргән укучының хатасына мөнәсәбәт белдерүе дә без гадәтләнгәннән аерылып тора. «Юк, дөрес түгел, утыр,» — дигән сүзләр юк.

Дәрестә берничә кагыйдәнең үтәлүе мәҗбүри. Беренче кагыйдә — татарча гына сөйләшү. 4 нче дәрестән башлап, укучыларөчен «рус теле

ябыла». Баштагы 3–4 атнада укытучы әле рус теленә мөрәҗәгать итә, чөнки яңа уеннарның кагыйдәләрен аңлатырга кирәк була. Рус телен дәрестә куллану акрынлап кими бара һәм 2 нче чиректә без инде тулысынча татар теленә күчәбез. Әмма шәхси тәҗрибәм шуны күрсәтә: балалар бу таләпне укытучы үзе әлеге кагыйдәне бозмаган очракта гына үтиләр, ул рус теленә күчсә, алар да шул телдә аралаша башлыйлар. Димәк, кагыйдәгә укытучы да буйсына.

Уенны кем алып бара, шул аңа җитәкчелек итә. Мәсәлән, балалар «мәктәп-мәктәп» уенын ярата. Без аны бик еш, дәрес саен диярлек уйныйбыз. Монда укытучы укучы ролендә булып, укучы урынына барып утыра, ә бала укытучы урынына баса.

Тел мохитенә чумдыру ничек башкарыла? Беренчесе — ул татарча гына сөйләшү мәҗбүриятен тудыру. Уенда катнашу өчен татарча ниндидер сүз әйтү кирәк. Һәм дәрестә русча сөйләшмәү таләбе дә эшли. Ә ничек сүз мәгънәсен җиткерергә соң? Моның өчен без күрсәтмәлелеккә басым ясыйбыз. Ул — рәсемнәр, уенчыклар да, тән, кул, йөз хәрәкәтләре дә. Аңлашу өчен, тел образын тудыру өчен бик кирәкле аралашу элементлары. Шуңа күрә ниндидер сүзне яки структураны хәрәкәт белән күрсәтәбез. Сүз, предмет, төшенчәләрне күрсәтү уңайсыз булган очракта, рәсем яки уенчык кулланабыз.

Тел мохитенә чумдыру гаҗәеп нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек тудыра. Мәсәлән, укучыларның дәрес тәмамлангач, укытучылар белән саф татарча исәнләшүләре, укытучыга татарча мөрәҗәгать итүләре:

— Ә синең песиең бармы? — *Минем песием бар.*

— Ул нинди? — *Ул ак, матур, ул зур, ул яхшы.*

— Ә ул кайда? — *Ул өйдә.*

— Син песиеңне яратасыңмы? — *Әйе, бик-бик яратам!*

Менә шундый диалоглар, кара-каршы сөйләшүләр бик еш була.

Сөйләм телен үстерү курсында укучыларның шәхси үсеше өчен шартлар тудыруга да әһәмият бирелә. Балаларда уеннан укуга күчү активлыгын формалаштырыла. Алар курыкмыйча такта янына чыгарга, төркем белән идарә итәргә өйрәнәләр. Даими рәвештә төрле рольләргә кереп уйнау (мәсәлән, сатучы, кибетче, укытучы һ.б.) социальләшүгә, ягъни төрле җәмгыяви структураларга кереп, шәхеснең продуктив үсешенә йогынты ясый.

Дәвамчанык һәм материалның гел кабатланып торуы материалның горизонталь тематик планлаштыруында чагылыш таба. Телнең теләсә кайсы

берәмлеге, сөйләм структурасы өч этаптан тора: ишетү, камилләштерү, ныгыту. Шул рәвешле, өйрәнгән материал кыска хәтердән озын хәтергә күчә, онытылып калмый.

Дәрес структурасы укучыларның эчке һәм тышкы активлыкларын саклануны куздә тотарга, ягъни һәр ике категория дә дәрестә үзләрен җайлы итеп хис итәргә тиеш булалар.

В.Н. Мещерякова системасындагы лексик берәмлекләр, сөйләм структуралары шулай итеп сайланган ки, алар көндәлек тормышта да һәм сөйләмдә дә иркен кулланырлык. Әйтик, без укучылар белән савыт-саба, ашамлык темаларын өйрәнгәндә, ашханәдә аралашканда:

«Кайда кашык? — *Менә, ал!»*

«Ипи бирегез, зинһар! — *Рәхмәт».*

«Аш тәмлеме*? — Әйе, тәмле*!» кебек структураларны кулландык. Иң элек мин укучыларымны сөйләмгә, аннан соң инде инициативалы балаларны, ягъни «тел бистәләрен», сөйләшүгә этәрдем. Монысы бигрәк тә кадерле.

*Икенче проект — мәгълүмати-коммуникатив технологияләргә нигезләнгән яңа буын «Сәлам!» УМКы.* «Сәлам!» укыту-методик комплекты (УМК) рус телендә башлангыч белем бирү оешмаларының 1нче сыйныф укучылары һәм татар телен башлап өйрәнүчеләр өчен тәкъдим ителә. Ул татар телен чит тел яки икенче тел буларак укыту методикасы нигезендә, коммуникатив принципны алга куеп төзелде, шунлыктан башлангыч сыйныф укучылары татар телен тормышчан һәм маҗаралы хәлләргә эләккән геройлар — яшьтәшләре һәм аларның дуслары белән бергә өйрәнәләр, күнегүләр башкаралар, бергә уйныйлар, җырлыйлар.

«Сәлам!» укыту-методик комплектының төп бурычы — дәрестә укучыларны сөйләшергә өйрәтү. Моңа алар уеннар уйнап, аудиодиалог һәм монологлар тыңлап, тормышчан ситуациядә үз-үзләрен тотышлары аша ирешәләр. Укучылар, уйный-уйный, яңа сүзләр, җөмләләр өйрәнәләр. Грамматик кагыйдәләр ятламыйлар. Беренче сыйныфта укучылар үз көндәлек тормышларында иң актив һәм кирәк булган 160 сүз һәм 30 сөйләм калыбы өйрәнәләр. 15 теманы берләштергән дәреслек, укучыларга иҗади мөмкинлекләр биргән эш дәфтәре, сайт аша өйдә дә уеннар уйный алу, аудиоязмаларны тыңлау, дәрестә үзләштерелгән сүзләр нигезендә язылган җырларны өйрәнү, кирәк булса дәрестә тыңлаган аудиоязмаларны өйдә дә аудиоязма яки сайт аша тыңлый алу — укучыларга телне өйрәнүдә ярдәм итәр дип уйлыйбыз.

*УМК түбәндәге компонентлардан тора:*

- дәреслек
- интерактив дәреслек
- эш дәфтәре
- укытучы китабы
- аудиодиск
- лексик карточкалар
- www.selam.tatar сайты

*Дәреслек* белән укучылар дәрестә эшлиләр. Ул төсле һәм матур рәсемле, балалар күңеленә хуш килердәй стильдә эшләнгән. Һәр дәрестә УМКның төп геройлары төрле вакыйгаларда катнашалар һәм укучыларны шул ситуациягә бәйле сөйләм калыплары белән таныштыралар. Дәреслек 15 темага бүленеп бирелә, һәр теманың үз эчендә дәресләргә бүленеш тә тәкъдим ителә. Укучыларны күнегүләр белән артык ялыктырмас өчен, дәрес саен 2–4 күнегү генә тәкъдим ителә, әмма «Укытучы китабы»нда бу күнегүләргә карата, сайлап алу һәм башкару өчен, төрле бирем үрнәкләре күрсәтелә.

*Интерактив дәреслек* укытучыга күнегүләрне укучылар белән күмәк эшләү, материалны зур планга чыгарып, дәрестә күрсәтмәлелекне арттыру, укучыга өйдә эти-әниләр белән бергә дәрес материалын кабатлау өчен уңайлыклар тудыра.

*Эш дәфтәре*ндәге иҗади биремнәрне балалар өйдә дә, дәрес вакытында да башкара алалар. Бу биремнәрне башкару балага үз фантазиясен күрсәтергә ярдәм итә, үз эшен бәяләргә өйрәтә. Укучылар эш дәфтәрендә рәсем ясый, үзе теләгәнчә аларны буйый, стикерлар ябыштырып, рәсемнәрне тулыландыра алалар. Эш дәфтәрендәге күнегүләрнең барысын да укучыга дәрестә яки өйдә эшләп бетерү максаты куелмый. Укытучы күнегүне баланың сәләте һәм теләгенә карап сайлап ала. Эш дәфтәренең ахырында күнегүләрне башкару өчен стикерлар җыелмасы бирелә.

*Укытучы китабында* һәр дәреснең барышын тасвирлаган материал тәкъдим ителә. Анда дәреслектәге күнегүләр, аудиоязма текстлары, укучыларга бирелә торган сорау үрнәкләре, дәрестә башкарылырга мөмкин булган уен үрнәкләре, укучыларны ял иттереп алу өчен, хәрәкәтчәнлек таләп иткән биремнәр, эш дәфтәрендәге биремнәрне башкаруга күрсәтмәләр, җыр текстлары һәм алар белән эшкә тәкъдимнәр күрсәтелә. Бу биремнәрнең саны дәрес саен төрле. Гадәттә алар, 60 минутка җитәрлек итеп биреләләр.

«Сәлам!» УМКсы 152 сәгатьлек дәрес материалын үз эченә ала. Төрле уку-укыту оешмаларында дәрес саннары төрлечә булганлыктан, укытучылар

тематик һәм календарь эш программаларын үзләренә яраклаштырып төзергә тиеш булалар.

Дәреслектә күнегүләр татар теле һәм әдәби уку дәресләренә бүлеп бирелми. «Укытучы китабы» нда исә әдәби уку дәресләрендә файдаланылырга мөмкин булган материал укытучы өчен искәртелеп барыла, аудио һәм видео материалларга сылтамалар тәкъдим ителә, укытучы тарафыннан укылырга киңәш ителгән текстлар бирелә.

www.selam.tatar — сайты. Татарча сөйләшү, татар телен үзләштерү мәктәптә генә түгел, ә өйдә дә дәвам итсен өчен, УМКның махсус сайты — «Сәлам» сайты эшли. Аңа компьютер аша да, планшет аша да кереп була. Сайтта интерактив дәреслек, барлык уку-укыту материаллары бар, күнегүләрне уен форматында эшләү мөмкинлеге каралган, әти-әниләрнең сораулары яки тәкъдимнәре булса, кара-каршы язышып, күнегүләргә һәм биремнәргә карата комментарийлар калдырып була. Сайт периодик рәвештә яңартылып тора, кирәкле материаллар белән тулыландырыла. Дәреслек сәхифәсенә укучы да, укытучы һәм әти-әни дә махсус логин һәм парольләр аша кереп эшли. Әлеге парольләр укытучы тарафыннан таратыла.

*Карточкалар*. Алда әйтелеп үтелгәнчә, укучылар 1нче сыйныфта уку дәверендә татар теле дәресләрендә 160 лексик берәмлек өйрәнәләр. Аларны төрле сөйләм калыпларында файдалана һәм кирәкле ситуацияләрдә куллана белергә тиеш булалар. Бу эшне җиңеләйтү максатыннан, укытучыга дәрестә куллану өчен, рәсемле карточкалар тәкъдим ителә. Аларның электрон вариантлары сайтта да урын ала. Бу карточкаларны «Укытучы китабы»нда киңәш ителгәнчә, гадәти дәрес барышында да, контроль дәресләрдә дә, өйдә материалны кабатлау өчен дә файдаланырга мөмкин.

УМКның файдалы үзенчәлеге — аудиоматериалларның күп булуы һәм сайтта күнегүләрне интерактив форматта эшләп булуда. УМКның һәр модулендәге бик күп үрнәк диалоглар, монологлар, җырлар укучыларга телне яратып өйрәнергә ярдәм итәр дип ышанабыз.

Рус мәктәбендә укучы татар балаларына әдәбият укытудагы үзгәрешләр дә нигездә сәгать саны кимүе белән бәйле. 2018/2019 уку елында татар әдәбиятын укыту буенча календарь-тематик план үзгәртелде. Шуңа нигезләнеп, 1–9 нчы сыйныфларда тәкъдим ителә торган материал кыскартылды.

Тематика нигездә үзгәрешсез калды, кайбер темалар гына тематик планлаштырудан чыгарылды. Әйтик, рус мәктәбендә укучы татар

балаларына әдәбият укыту буенча 7нче сыйныф программасыннан «Фантастиканың серле дөньясы» исемле тема тулаем алынды.

Өйрәнү өчен әдәби әсәрләрне сайлаган вакытта, иң беренче чиратта, минимум (мәҗбүри) өлеш исәпкә алынды. Программада минимум өлештә тәкъдим ителгән әдәби әсәрләр һәм шулай ук язучылар биографиясе яңартылган тематик планлаштыруга тулысы белән кертелде. Өстәмә уку өчен әдәбият өлешендә күпчелек очракта татар әдәбияты классиклары әсәрләре, һәм аларның биографияләре сайлап алынды. Биредә шуны искәртү сорала, сәгатьләр кыскартылу сәбәпле аерым очракларда язучыларның тормыш юлы һәм иҗатын өйрәнү күздә тотылмый (бу очракта яки язучының биографиясе алдагы елларда инде өйрәнелүе, яки аерым теманы өйрәнүгә сәгать кимәтелү сәбәпле теманың программадан чыгарылуы исәпкә алынды).

Өйрәнү өчен әсәрләр билгеле бер яшьтәге укучыларның сөйләм телен үстерү, сүзлек байлыгын арттыру да күздә тота. Шулай ук телне өйрәнүнең коммуникатив приципларын тәэмин итү ягын да онытмаска кирәк. Өйрәнү өчен әдәби әсәрләр шулай ук уку өчен кызыклы булулары ягыннан да, яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып та сайланды. Сайланган әдәби әсәрләрнең аңлау өчен артык авырлык тудырмаулары да истә тотылды. Мәсәлән, 6 нчы сыйныфта тематик планлаштырудан Г.Кандалыйның «Мулла һәм абыстай» шигыре алынды. Кандалый иҗатыннан укучыларга кызыклырак булган афоризмнарын өйрәнү тәкъдим ителде.

Шул ук вакытта тематик планлаштыруда укучыларга үзләштерү өчен кыенлыклар тудырырга мөмкин булган әсәрләр бар. Әйтик, Борынгы һәм Урта гасыр, XVII, XVIII, XIX чор татар әдәбиятларына караган темалар авыр, әмма бу темаларны өйрәнми калу мөмкин түгел, чөнки төп мәктәп курсында татар әдәбияты турында гомуми күзаллау формалаштыру максаты белән Борынгы чордан алып бүгенге көнгә кадәр әдәбият тарихын өйрәнү күздә тотыла.

Бүген рус һәм татар мәктәпләрендә татар әдәбиятын укыту яңа ысул-алымнар куллануны таләп итә. Билгеле булганча, балаларның хәзерге вакытта фикер йөртү рәвеше, фикерләрен башкаларга җиткерү, аралашу дәрәҗәсе үзгә. Балаларның компьютер технологияләре белән мавыгуы аларның аралашу даирәсен чикли. Нәтиҗәдә татар әдәби телендә фикерләрен тиешле дәрәҗәдә аңлаешлы, төзек, дөрес җиткерә алучы балалар кимегәннән-кими бара. Моны алга таба булдырмас өчен татар теле дәресләре белән беррәттән әдәбият дәресләрендә дә әдәби әсәрләрне уку барышында шуларның эчтәлеге нигезендә фикерләп, монологлар төзү, диалогларда актив

катнашу, татар мәктәпләрендә билгеле бер темага фикер алышу ярдәмгә килә ала. Әдәби белем бирү белән беррәттән әдәбият дәресләрендә укучыларның сөйләм телләрен үстерү максаты бүгенге көндә иң актуаль мәсьәләләрнең берсе булып санала. Моннан тыш татар балаларыбызның (бүгенге көндә, ни кызганыч, бу күренеш хәтта саф татар авылларында да күзәтелә башлады) татар телендә иркен сөйләшә алмаулары да көн үзәгендәге проблемага әверелде.

Аралашу, сөйли белү күнекмәләре укучының коммуникатив компетенциясе белән бәйле. Коммуникатив компетенция сөйләм эшчәнлеге төрләрен формалаштыруның мөһим шарты булып тора. Коммуникатив компетенция ул — кешенең төрле даирәдә һәм аралашу ситуацияләрендә теге яки бу коммуникатив бурычларны тел чаралары ярдәмендә хәл итү сәләте. Укытуның коммуникатив максатын гамәлгә ашыру сөйләм эшчәнлегенең аның барлык төрләрендә дә уку, сөйләү, язу, тыңлау вакытында формалаштыруны аңлата. Коммуникатив гамәлләр, бер яктан, максат, мотив, бурычлар белән бәйле рәвештә аралашуны оештыру, икенче яктан, сөйләм эшчәнлегенең социаль нормалары белән тәңгәллегенә ирешүгә бәйләнгән була. Бу очракта практик максат — аралашу күнекмәләрен формалаштыру беренче планга чыга.

«Тулы канлы аралашу булсын өчен, кеше шактый күп күнекмәләргә ия булырга тиеш», — дип саный психологлар. Беренчедән, аралашу шартларында тиз һәм дөрес ориентлашырга, икенчедән, үз сөйләмен тиз һәм дөрес планлаштырырга, аралашу гамәленең эчтәлеген дөрес сайларга, өченчедән, бу эчтәлекне тапшыруның тиешле чараларын табарга тиеш. Аралашу гамәле чылбырында кайсыдыр буын өзелсә, сөйләүче һәм тыңлаучы да аралашудан көткән нәтиҗәләргә ирешә алмаячак.

Коммуникатив күнекмәләрне формалаштыру таләбе, иң беренче чиратта, тел дәресләренә бәйле, шул ук вакытта әдәбият дәресләре дә коммуникатив уку гамәлләрен формалаштыруда зур мөмкинлекләргә ия.

Коммуникатив универсаль уку гамәлләре җәмгыятькә мөнәсәбәтле осталык һәм башка кешеләрнең (әңгәмәдәш, хезмәттәш) позицияләрен исәпкә алуны тәэмин итә; тыңлый белү һәм диалогка керү; проблемаларны бергәләп тикшерүдә катнашу; яшьтәшләре төркеменә кушыла алу һәм алар, өлкәннәр белән бердәм хәрәкәт, алар белән хезмәттәшлек итә алу осталыгы булдыра.

Коммуникатив уку гамәлләре укытучы һәм сыйныфташлар белән укуда хезмәттәшлекне планлаштыру һәм оештыру — максатын, катнашучыларның

вазифаларын, алымнарын билгеләү; сораулар бирә белү — информация эзләү һәм туплауда хезмәттәшлек итү; конфликтларны чишү — проблеманы ачыклау, тәңгәлләштерү, аны хәл итүнең альтернатив юлларын эзләү һәм бәяләү, карар кабул итү һәм аны тормышка ашыру; әңгәмәдәшнең тәртибенә җитәкчелек итү — аның гамәлләрен күзәтү, төзәтү һәм бәяләү; аралашу максатына туры китереп, үз фикереңне җитәрлек дәрәҗәдә тулы һәм төгәл, ачык һәм дөрес итеп әйтә белү; тел нормаларына туры китереп, монолог төзү һәм диалогта катнашу осталыгына ия булуны аңлата. Шулай ук коммуникатив уку гамәлләренә тыңлый һәм башкаларның сорауларына җавап бирү, үз фикерләрен тәгъбир итү, үзенең карашын әйтү һәм дәлилләү, үз позициясен тәгъбир итү, коммуникатив мәсьәлә белән бәйле рәвештә сөйләм чараларын куллану, төп күренешләрнең һәм эпизодларның эчтәлеген сөйләү, парларда һәм төркемнәрдә конкрет уку-танып-белү мәсьәләләре белән бәйле рәвештә бергәләп эшләү, эчтәлек сөйләү күнекмәләрен үстерү, укылганга телдән рецензия төзү, сөйләм нормаларын исәптә тотып, укытучы, сыйныфташлар белән уку диалогы алып бару, үз фикерләрен тәгъбир итү, эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштыру кирә.

Әдәбият дәресләренең төп бурычларының берсе булып укучыларны матур, төзек, төгәл, дөрес итеп сөйләргә өйрәтү тора. Бу, үз чиратында, әдәбиятны яхшырак, тирәнрәк аңлау-төшенүгә ачкыч ролен үти.

Укучыларны аралашу эшчәнлегенә тарту өчен әдәби әсәр текстларыннан файдаланыла. Әдәби әсәр теле укучыларны әдәби телдә сөйләргә өйрәтү, телнең матурлыгын, байлыгын аңлау өчен бик файдалы була ала. Шуны да истә тотарга кирәк, кешенең телдән һәм язмача сөйләм дәрәҗәсе аның фикер йөртү дәрәҗәсенә бәйле.

Мәктәптә әдәби белем бирү сөйләм үстерү белән бергә алып барыла. Сөйләм үстерү өчен махсус сәгатьләр бүленеп бирелә. Шул ук вакытта һәрдаим дәрестән дәрескә әдәбиятны өйрәнү барышында бу эш башкарыла бара.

Әдәби әсәрне өйрәнү дәресендә сөйләм үстерү берничә төрле башкарыла ала. Әсәр белән танышу барышында укучы әсәрне укыганда укучыдан текстны аңлап уку таләп ителә. Аңлаганнарын әсәр турындагы беренче тәэсирләрен уртаклашу вакытында белеп була. Бу вакытта кыска гына җавапларга канәгать булып калмыйча, укучыларның фикерләре мөмкин кадәр тулы, төзек булуына ирешү сорала. Балаларның ни дәрәҗәдә укыганнарын аңлауларын шулай ук әсәрнең эчтәлеген сөйләгән вакытта белеп була. Эчтәлек сөйләү сөйләм телен үстерүдә әһәмиятле алым булып

санала. Эчтәлек сөйләү ул укыганны яңадан хәтердә тергезеп кабатлап сөйләү дигән сүз. Бу укучыга мөстәкыйль сөйләмен баетырга, эзлекле, матур һәм стилистик яктан дөрес төзергә ярдәм итә. Бу алымны кулланып эшләгәндә эчтәлек сөйләүнең төрләреннән сюжетны кыскача сөйләү, аерым вакыйгаларның эчтәлеген сөйләү, кайбер өлешләргә мөнәсәбәт белдереп сөйләү, эчтәлекне иҗади сөйләү, текстка якын итеп сөйләү (лирик әсәрне өйрәнгәндә, мәсәлән), планга нигезләнеп сөйләү кулланыла ала.

Эчтәлек сөйләгәндә текстта урын алган образлы гыйбарәләрне, аерым лексиканы, синтаксик конструкцияләрне кулланып сөйләү шарт булып тора. Шулай ук укучыдан хикәяләүнең эзлеклелеген, билгеле бер тәртипне, логиканы бозмауны таләп итәргә кирәк. Укучы текстның эчтәлеген эмоциональ итеп сөйләсә, тыңлаучыга сөйләгәннәрне аңлавы җиңелрәк булачагын истә тотарга тиеш.

Балага эчтәлек сөйләү билгеле бер авырлыклар тудыра икән, план буенча, ягъни ачкыч (төп) моментларны билгеләп сөйләтеп була. Сөйләгәндә текстны кыскартуны мөмкин кадәр чикләргә кирәк. Укучыга төп фикерләрне билгеләп, текстны җиңелдән катлаулыга таба, ягъни киңәйтеп сөйләргә өйрәтү мөһим.

Шунысы да әһәмиятле, эчтәлек сөйләүче укучының механик рәвештә ятланган текст итеп түгел, ә бәлки аның җанлы сөйләвенә ирешергә кирәк. Шул ук вакытта эчтәлек сөйләгәндә авторның үрнәк стиле дә сакланырга тиеш. Укучылар тарафыннан сөйләнгән эчтәлек дөрес сөйләм формалаштыра, әдәби зәвыкны, телне тоюны үстерә, укучыларның әхлакый-эстетик сыйфатларын формалаштыра.

Укучы сөйләргә башкаларны тыңлау аша өйрәнә. Баланы сөйләмне тыңларга, кабул итәргә өйрәтергә кирәк. Монологик сөйләмдә иң әһәмиятлесе — мәгънә, эчтәлек. Телдән сөйләмне кабул итәргә өйрәтүне иң элек ишетеп аңлаудан башларга кирәк. Сөйләгәнне тыңлаган вакытта фактларны язып алу, план һәм тезислар төзү, конспектлаштыру һ.б. шундый эш төрләреннән файдалану яхшы нәтиҗә бирә.

Актив тыңлау алымнарына 5 нче сыйныфтан ук өйрәтә алабыз. Мәсәлән, кереш дәрестә үк тактага укытучының сөйләвендә очрый торган аерым сүзләрне (ачкыч сүзләрне) язып куябыз. Бу сүзләр укучыга игътибарын төп моментларга юнәлтү, укытучының зур булмаган лекциясен игътибар белән нәтиҗәле тыңлау мөмкинлеген бирә. Алга таба 6 нчы сыйныфта ачкыч сүзләрне, даталар белән катлауландырып бирергә мөмкин. Бу, үз чиратында, укучыларга укытучының сөйләвен яхшырак итеп истә

калдырырга, алга таба хәтердә тергезеп дөрес, төгәл итеп сөйләү мөмкинлеген бирәчәк. Укучыларның сөйләвендә гади җөмләләрне генә кулланып калмыйча, катлаулы җөмләләрне кушып сөйләү таләп итү сорала.

Әңгәмәдә (диалогта) катнашу алу осталыгы җавап бирә бирә белүдә чагылыш таба. Укучы дөрес, тулы, төгәл, җавап бирсен өчен укытучыга аның җавабына һәрдаим игътибар бирергә тиеш. Кирәк булганда төзәтергә, ачыкларга, хупларга да кирәк. Укучылардан кыска җавап түгел, ә киңәйтелгән җавап алуга ирешү мөһимлеген бик яхшы аңлыйбыз. Бу вакытта балаларның кыска җавапларын киңәйтелгән җаваплар белән чагыштырып күрсәтеп өйрәтү отышлы санала. Укучылар аерманы күрәләр, тулы җавап бирүнең әһәмиятен аңлыйлар һәм алга таба шул рәвешле тулы итеп җавап бирергә күнегәләр. Шулай ук сорау бирергә өйрәтү дә әһәмиятле санала. Моның өчен үзара аралашуда, әңгәмә барышында мөмкин кадәр укучыларга бер-берсенә сорау бирү мөмкинлеген тәэмин итәргә кирәк.

Бәйләнешле сөйләм үстерүдә хикәя төзү, тасвирлап хикәяләү, рәсем-иллюстрацияләр, караган спектакль, кинофильмнар, укылган китап буенча сөйләү дә нәтиҗәле алым булып тора. Мондый сөйләү булганда образлы сөйләмгә игътибар итү зарур, төрле сурәтләү чараларын кулланып сөйләү, логик эзлеклекне саклау да — болар барысы хикәяләүнең нәтиҗәлелеген тәэмин итәчәк.

Алда әйтелгәннәр килеп туган каршылыкларны үтеп чыгарга, әдәбият фәнен укытуның нәтиҗәлелеген арттырырга ярдәм итәчәк.

Мәктәптә әдәбиятны өйрәнү аны рухи-эстетик кыйммәт буларак аңларга,әдәбиятның идея-эстетик байлыгын үзләштерергә, классик әдәбият үрнәкләре белән танышырга, әдәби әсәрләрне анализларга һәм бәяләргә өйрәнергә, танылган язучыларның тормыш юлы һәм иҗаты турында күзаллау булдырырга, әдәби әсәрнең образлылыгын аңлау барышы нигезендә коммуникатив күнекмәләр үстерергә һәм камилләштерергә мөмкинлек бирә.

# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУЧЫСЫ ЭШЧӘНЛЕГЕН БИЛГЕЛИ ТОРГАН НОРМАТИВ ДОКУМЕНТЛАР

Татарстан Республикасында телләр өйрәнүнең хокукый нигезләре Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив документлары белән раслана.

*Россия Федерациясендә гамәлдә булган норматив документлар:*

— Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә белем бирү турында»гы Законы (Федеральный закон «Об образовании в Российской Федерации»(29.12.2012, № 273-ФЗ);

— Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе халык телләре турында» гы Законы (Закон РФ «О языках народов Российской Федерации» (25.10.1991, № 1807-1, ред. 12.03.2014);

— Россия Федерациясе Президентының «2012–2017 елларга балалар мәнфәгатендә милли стратегия хәрәкәтләре турында»гы 761 нче номерлы Указы (Указ Президента Российской Федерации «О национальной стратегии действий в интересах детей на 2012–2017 годы») (01.06.2012);

— Россия Федерациясе хөкүмәтенең 996-р номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясендә 2025 елга кадәр тәрбия бирү үсеше стратегиясе (Стратегия развития воспитания в Российской Федерации на период до 2025 года, утвержденная распоряжением Правительства Российской Федерации) (29.05.2015);

— 2015–2020 елларга белем бирү үсешенең максатчан федераль программасы (Федеральная целевая программа развития образования на 2015–2020 годы);

— Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2403-р номерлы боерыгы белән расланган 2025 елга кадәр дәүләт яшьләр сәясәте нигезләре (Основы государственной молодежной политики Российской Федерации на период до 2025 года, утвержденные распоряжениемПравительства Российской Федерации от 29 ноября 2014 г. №2403-р.).

Алда санап кителгән федераль документлар Россия Федерациясендә белем бирү сәясәтенең төп принципларын һәм юнәлешләрен билгелиләр, шулар нигезендә милли мәгариф эшчәнлеге дә тормышка ашырыла. Документлар укытучыларның илнең инновацион үсеше таләпләренә туры килгән сыйфатлы белем бирүне тәэмин итүләренә һәм белем бирү

системасының милли-төбәк мәдәниятен һәм традицияләрне үстерүгә юнәлдерелгәннәр.

*Татарстан Республикасында гамәлдә булган норматив документлар:*

— Татарстан Республикасының «Мәгариф турында»гы Законы (Закон Республики Татарстан от 22 июля 2013 года № 68-ЗРТ «Об образовании»);
— «Татарстан Республикасының халык телләре турында» Законы (Закон Республики Татарстан от 8 июля 1992года №1560 – XII «О государственных языках Республики Татарстан и других языках в Республике Татарстан» (с учетом новой редакции Закона Республики Татарстан от 12 июня 2014 г. №53 — 3 РТ «О внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан»);
— «2014–2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы» (25.10.2013, 794 нче карар);
— Татарстан Республикасында 2012–2020 нче елларда фән һәм мәгариф үсеше турында «Дәүләт программасы»;
— 2016 елның 19 нчы августында ТР Министрлар Кабинетының 570 нче карары нигезендә расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында Милли мәгарифне үстерү концепциясе.

Норматив документлар буенча мәгълүматларны түбәндәге сайтлардан табарга мөмкин:

http://минобрнауки.рф (РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы);

http://www.edu.ru («Российское образование» федераль порталы);

http://mon.tatarstan.ru (ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы);

http://www.irort.ru (ТР Мәгарифне үстерү институты)

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыклары белән төп гомуми белем бирүнең өч федераль дәүләт белем бирү стандарты (башлангыч гомуми белем бирү — № 373, 06.10.2009 ел; төп гомуми белем бирү — № 1897, 17.12.2010 ел; урта (тулы) гомуми белем бирү — №413, 17.05.2012 ел) расланды.

Төп гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем стандартлары (ФДББС) мәгариф системасына баскычлап кертелә. Башлангыч гомуми белем бирү баскычында федераль дәүләт белем бирү стандарты 2011/2012 уку елыннан гамәлгә кертелде. Ә төп гомуми белем бирү баскычында яңа

буын белем бирү стандартына күчү 2015/2016 уку елыннан, урта (тулы) гомуми белем бирү баскычында — 2020/2021 уку елыннан тормышка ашырылачак.

ФДББС — дәүләт аккредитациясенә ия булган башлангыч, гомуми, төп гомуми, урта гомуми, башлангыч һөнәри, урта һөнәри белем бирү оешмалары тарафыннан төп укыту программаларын гамәлгә куйганда, мәҗбүри рәвештә үтәлергә тиешле дәүләт таләпләре җыелмасы.

ФДББС түбәндәгеләргә таләпләрне куя:

— төп белем бирү программаларының төзелешенә;

— төп белем бирү программаларын гамәлгә кую шартларына.

— төп белем бирү программаларын үзләштерү нәтиҗәләренә.

Бу таләпләр белем бирүнең һәр баскычында укучыларның яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен искә алып үтәләләр.

ФДББСның методологик һәм эчтәлек нигезләре түбәндәге документларда чагылыш таба:

— «Төп гомуми белем бирүнең федераль дәүләт стандартлары концепциясе» («Концепция федеральных государственных стандартов общего образования»);
— «Гомуми белем бирү эчтәлегенең федераль төше» («Фундаментальное ядро содержания общего образования»/ под ред. В.В. Козлова, А.М. Кондакова. — М.: Просвещение, 2009);
— «Россия гражданины шәхесен рухи-әхлакый яктан үстерү һәм тәрбияләү концепциясе» (Концепция духовно-нравственного развития и воспитания личности гражданина России: учебное издание / А.Я. Данилюк, А.М. Кондаков, В.А. Тишков. — М.: Просвещение, 2010).

Әлеге документлар белән Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтында «Федераль дәүләт белем бирү стандартлары» бүлегендә танышырга мөмкин: http://минобрнауки.рф/документы/543.

Россия Федерациясендә туган телне һәм дәүләт телләрен саклау һәм үстерү өчен кирәкле норматив-хокукый база булдырылган, Татарстан Республикасында тиешле оештыру-идарә итү, фәнни-методик, кадрларга кагылышлы шартлар тудырылган. Кабул ителгән норматив документларга нигезләнеп, татар теле һәм татар әдәбияты гомуми белем бирү системасында туган тел һәм туган телдәге әдәбият, шулай ук дәүләт теле һәм чит телле әдәбият буларак, мәктәпкәчә белем бирү, гомуми белем бирү оешмаларының 1–11 сыйныфларында өч юнәлештә өйрәнелә:

— татар телендә гомуми белем бирүче оешмаларда татар теле һәм татар әдәбияты;

— рус телендә гомуми белем бирүче оешмаларда татар теле һәм татар әдәбияты (татар укучылары өчен);

— рус телендә гомуми белембирүче оешмаларда татар теле һәм татар әдәбияты (рус телле укучылар өчен).

Һәр юнәлеш буенча үрнәк эш программалары төзелгән, УМКлар эшләнгән; татар теле һәм татар әдәбияты укытучыларын әзерләү тормышка ашырыла; педагогларга өстәмә һөнәри белем бирү эше оештырылган»[1].

Белем бирү оешмаларында түбәндәге уку программалары кулланыла:

— белем бирү оешмасының төп белем бирү үрнәк программасы;

— уку предметы буенча авторлык программасы;

— уку предметы буенча эш программасы.

Татар телен һәм әдәбиятын укыту V–XI сыйныфлар өчен «Татар теле» һәм «Татар әдәбияты» буенча Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган өч юнәлештәге үрнәк программаларга нигезләнә. 2017/2018 уку елларында ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының http://mon.tatarstan.ru сайтында урнаштырылган үрнәк программалар, УМКлар, кулланмалардан файдаланырга тәкъдим ителә. ТР Мәгарифне үстерү институты татар теле һәм әдәбияты кафедрасы хезмәткәрләре тарафыннан эшләнгән методик әсбапларда татар телен һәм әдәбиятын укыту буенча файдалы киңәшләр бирелә (Тәкъдим ителгән әдәбият исемлеген кара).

[1] Татарстан Республикасында 2030 елга кадәр Милли мәгарифне үстерү концепциясе

# ТАТАР ТЕЛЕН ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ БУЛАРАК УКЫТУНЫ ТӘЭМИН ИТӘ ТОРГАН УКЫТУ-МЕТОДИК КОМПЛЕКТЛАРЫНА КҮЗӘТҮ

Мәктәптә туган телне (татар телен) һәм туган тел әдәбиятын укытуны укыту-методик тәэмин ителеше Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган дәреслекләрнең федераль исемлеге нигезендә тормышка ашырыла. 2018/2019 уку елында белем бирү оешмалары Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган «Дәреслекләрнең Федераль исемлеге» боерыгы (18.07.2016, №870) нигезендә яңа федераль исемлеккә кертелгән дәреслекләр буенча укый алачаклар:

| **Башлангыч гомуми белем бирү** | | | |
|---|---|---|---|
| Туган тел (уку предметы) | | | |
| Гарифуллина Ф.Ш.,<br>Мияссарова И.Х. | Әлифба | 1 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Харисов Ф.Ф.,<br>Сираҗиева Г.Д. | Татар теле | 1 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Харисов Ф.Ф.,<br>Харисова Ч.М.,<br>Панова Е.А. | Татар теле | 2 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Харисов Ф.Ф.,<br>Шакирова Г.Р.,<br>Сәгъдиева Р.К.,<br>Хисматова Л.К. | Татар теле | 3 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Харисов Ф.Ф.,<br>Харисова Ч.М.,<br>Сәгъдиева Р.К.,<br>Гарипова В.А. | Татар теле | 4 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Җамалетдинова З.И. | Татар теле: татар телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек | 1 | Татарстан китап нәшрияты |
| Җамалетдинова З.И. | Татар теле: татар телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек | 2 | Татарстан китап нәшрияты |
| Җамалетдинова З.И. | Татар теле: татар телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек | 3 | Татарстан китап нәшрияты |
| Җамалетдинова З.И. | Татар теле: татар телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек, 2 кисәктә | 4 | Татарстан китап нәшрияты |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Мияссарова И.Х.,<br>Гарифуллина Ф.Ш.,<br>Шәмсетдинова Р.Р. | Алифба | 1 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Мияссарова И.Х.,<br>Харисова Ч.М. | Татар теле | 1 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Мияссарова И.Х.,<br>Фәйзрахманова К.Ф. | Татар теле, 2 кисәктә | 2 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Мияссарова И.Х.,<br>Фәйзрахманова К.Ф. | Татар теле | 3 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Мияссарова И.Х.,<br>Фәйзрахманова К.Ф. | Татар теле, 2 кисәктә | 4 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Фәтхуллова К.С. | Татар теле: рус телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек | 1 | Татарстан китап нәшрияты |
| Фәтхуллова К.С. | Татар теле: рус телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек, 2 кисәктә | 2 | Татарстан китап нәшрияты |
| Фәтхуллова К.С. | Татар теле: рус телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен | 3 | Татарстан китап нәшрияты |
| Фәтхуллова К.С. | Татар теле: рус телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен, 2 кисәктә | 4 | Татарстан китап нәшрияты |
| Харисов Ф.Ф.,<br>Харисова Ч.М. | Татар теле: рус телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен | 1 | Татарстан китап нәшрияты |
| Харисов Ф.Ф.,<br>Харисова Ч.М.,<br>Җәләлиева А.К. | Татар теле: рус телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен | 2 | Татарстан китап нәшрияты |
| Харисов Ф.Ф.,<br>Хисамова Ф.М.,<br>Харисова Ч.М. | Татар теле: рус телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен | 3 | Татарстан китап нәшрияты |
| Харисов Ф.Ф.,<br>Харисова Ч.М. | Татар теле: рус телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен | 4 | Татарстан китап нәшрияты |
| Хәйдәрова Р.З.,<br>Галиева Н.Г. | Татар теле: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен | 1 | «Татармультфильм» нәшрияты |
| Хәйдәрова Р.З.,<br>Галиева Н.Г.,<br>Әхмәтҗанова Г.М. | Татар теле: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен | 2 | «Татармультфильм» нәшрияты |
| Хәйдәрова Р.З.,<br>Әхмәтҗанова Г.М., | Татар теле: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен, 2 | 3 | «Татармультфильм» нәшрияты |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Гиниятуллина Л.А. | кисәктә | | |
| Хәйдәрова Р.З., Әхмәтҗанова Г.М., Гиниятуллина Л.А. | Татар теле: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен, 2 кисәктә | 4 | «Татармультфильм» нәшрияты |
| Туган телдә әдәби уку (уку предметы) | | | |
| Гарифуллина Ф.Ш., Мияссарова И.Х. | Әдәби уку | 1 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Гарифуллина Ф.Ш., Мияссарова И.Х. | Әдәби уку, 2 кисәктә | 2 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Гарифуллина Ф.Ш., Мияссарова И.Х. | Әдәби уку, 2 кисәктәуку) в 2 частях | 3 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Гарифуллина Ф.Ш., Мияссарова И.Х. | Әдәби уку, 2 кисәктә | 4 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Сафиуллина Г.М., Гарифуллина М.Я., Мөхәмәтҗанова А.Г., Хәсәнова Ф.Ф. | Әдәби уку, 2 кисәктә | 1 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Сафиуллина Г.М., Гарифуллина М.Я., Мөхәмәтҗанова А.Г., Хәсәнова Ф.Ф. | Әдәби уку, 3 кисәктә | 2 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Сафиуллина Г.М., Мөхәмәтҗанова А.Г., Хәсәнова Ф.Ф. | Әдәби уку, 3 кисәктә | 3 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Сафиуллина Г.М., Мөхәмәтҗанова А.Г., Хәсәнова Ф.Ф. | Әдәби уку, 3 кисәктә | 4 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Рус телендә гомуми белем бирүче оешмалар өчен | | | |
| Рус төркемендә укучылар өчен | | | |
| Хәйдәрова Р.З. һ.б. | Татар теле. ФДББС | 5 | «Татармультфильм» нәшрияты |
| Хәйдәрова Р.З. һ.б. | Татар теле. ФДББС | 6 | «Татармультфильм» нәшрияты |
| Хәйдәрова Р.З. һ.б. | Татар теле. ФДББС | 7 | «Татармультфильм» нәшрияты |
| Хәйдәрова Р.З. һ.б. | Татар теле. ФДББС | 8 | «Татармультфильм» нәшрияты |
| Хәйдәрова Р.З. һ.б. | Татар теле. ФДББС | 9 | «Татармультфильм» нәшрияты |
| Мотыйгуллина Ә.Р., Хан-нанов Р.Г. һ.б. | Әдәбият. ФДББС | 5 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Мотыйгуллина Ә.Р., Хан-нанов Р.Г. һ.б. | Әдәбият. ФДББС | 6 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Мотыйгуллина Ә.Р., Ханнанов Р.Г. һ.б.. | Әдәбият. ФДББС | 7 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Мотыйгуллина Ә.Р., Ханнанов Р.Г., Вәлиуллина Р.Х. | Әдәбият. ФДББС | 8 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Мотыйгуллина Ә.Р., Ханнанов Р.Г., Хөснуллина Х.Х. | Әдәбият. ФДББС | 9 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Татар төркемендә укучылар өчен | | | |
| Шәмсетдинова Р.Р., Һадиева Г.К., Һадиева Г.В. | Татар теле. ФДББС | 5 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Сәгъдиева Р.К., Гарапшина Р.М., Хәйруллина Г.И. | Татар теле. ФДББС | 6 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Сәгъдиева Р.К., Харисова Г.Ф., Сабирҗанова Л.К., Нуриева М.А.. | Татар теле. ФДББС | 7 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Сәгъдиева Р.К., Хәйруллина Г.И. | Татар теле. ФДББС | 8 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Сәгъдиева Р.К., Кадыйрова Э.Х. | Татар теле. ФДББС | 9 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Хәсәнова Ф.Ф., Сафиуллина Г.М., Гарифуллина М.Я., Сафиуллина А.Н. | Әдәбият. ФДББС | 5 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Хәсәнова Ф.Ф., Сафиуллина Г.М., Гарифуллина М.Я., Сафиуллина А.Н. | Әдәбият. ФДББС | 6 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Хасанова Ф.Ф., Сафиуллина Г.М., Гарифуллина М.Я., Сафиуллина А.Н. | Әдәбият. ФДББС | 7 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Хәсәнова Ф.Ф., Сафиуллина Г.М., Гарифуллина М.Я., Сафиуллина А.Н. | Әдәбият. ФДББС | 8 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |
| Хәсәнова Ф.Ф., Сафиуллина Г.М., Гарифуллина М.Я., Сафиуллина А.Н. | Әдәбият. ФДББС | 9 | «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты |

| Татар телендә гомуми белем бирүче оешмалар өчен | | | |
|---|---|---|---|
| Харисова Ч.М., Максимов Н.В., Сәйфетдинов Р.Р. | Татар теле. ФДББС | 5 | Татарстан китап нәшрияты |
| Йосыпов Ф.Ю., Харисова Ч.М., Сәйфетдинов Р.Р. | Татар теле. ФДББС | 6 | Татарстан китап нәшрияты |
| Максимов Н.В., Набиуллина Г.А. / М.З. Зәкиев ред. | Татар теле. ФДББС | 7 | Татарстан китап нәшрияты |
| Зәкиев М.З. | Татар теле. ФДББС | 8 | Татарстан китап нәшрияты |
| Зәкиев М.З. | Татар теле. ФДББС | 9 | Татарстан китап нәшрияты |
| Ганиева Ф.А., Сабирова Л.Г. | Әдәбият. ФДББС | 5 | Татарстан китап нәшрияты |
| Ганиева Ф.А., Гарифуллина М.Д. | Әдәбият. ББФДС | 6 | Татарстан китап нәшрияты |
| Абдуллина Д.М., Хисматова Л.К., Җәүһәрова Ф.Х. | Әдәбият. ФДББС, 2 кисәктә | 7 | Татарстан китап нәшрияты |
| Ганиева Ф.А., Рамазанова Ч.Р. | Әдәбият. ФДББС, 2 кисәктә | 8 | Татарстан китап нәшрияты |
| Закирҗанов А.М., Миңнегулов Х.Ю., Фәхретдинова Г.М. | Әдәбият. ФДББС, 2 кисәктә | 9 | Татарстан китап нәшрияты |

Болардан тыш әлеге сыйныфларда татар телен һәм әдәбиятын укыту буенча электрон дәреслекләр, укытучы өчен методик әсбаплар, эш дәфтәрләре дә бар.

2018/2019 нчы уку елында татар телен дәүләт теле һәм татар әдәбиятын чит әдәбият буларак укыту буенча эш программалары һәм календарь-тематик планнар ТР МҮИ сайтында РУМО бүлегендә (http://www.irort.ru) урнаштырылган.

## ПЛАНЛАШТЫРГАН НӘТИҖӘЛӘРГӘ ИРЕШҮ

Федераль дәүләт гомуми белем бирү стандарты белем бирү процессының эчтәлеген яңарту, аның нәтиҗәләрен югары сыйфатлы итү максатын куя һәм шуның нигезендә укытучыларга укучыларда милли кыйммәтләр урнаштыру, белем бирүдә планлаштырылган нәтиҗәләрне һәм универсаль уку гамәлләрен формалаштыру, бәяләү системасын камилләштерү бурычлары йөкләнә. Укытуда предмет нәтиҗәләрен генә түгел, ә шәхескә караган һәм метапредмет нәтиҗәләрен (универсаль уку гамәлләрен) булдыру буенча эш алып барыла. Белем бирү процессында укучыда универсаль уку гамәлләрен формалаштыра алсак, бала мәктәптә алган белем-күнекмәләрне алдагы тормышта да куллана алачак, үз-үзенә ышанган, мөстәкыйль эш итә торган, коммуникатив, рухи дөньясы бай, кешелекле шәхес буларак тәрбияләнәчәк.

Татар телен һәм әдәбиятын укытуда шәхескә караган нәтиҗәләрне формалаштыру укучыларның түбәндәге сыйфатларга ия булуы белән билгеләнә:

— татар телен шәхеснең интеллектуаль, иҗади сәләтләрен, әхлак сыйфатларын камилләштерүдә ролен билгели торган татар халкының төп милли-мәдәни кыйммәте итеп тану;
— татар теленең эстетик кыйммәтен аңлау; туган телгә карата тирән ихтирам, аның өчен горурлык хисе барлыкка килү; татар теленең чисталыгын саклау ихтыяҗы булу; татар телендә грамоталы сөйләшергә омтылу;
— аралашу процессында фикерләрне һәм хисләрне иркен белдерү өчен җитәрлек сүз запасына һәм грамматик чараларга ия булу; үз сөйләмеңне күзәтү нигезендә үзбәягә сәләтле булу (рефлексия).

Метапредмет нәтиҗәләре — баланың белем алуга сәләтен һәм алган белемнәрен практикада куллана белү осталыгын булдыра торган универсаль уку гамәлләре комплексы.

Универсаль уку гамәлләре — субъектның яңа социаль тәҗрибәне аңлы һәм актив рәвештә үзләштерү юлы белән үзүсешкә һәм үзен камилләштерүгә сәләте, ягъни укучының белем алу процессын оештыра алуы. Универсаль уку гамәлләре системасын түбәндәге компонентлар тәшкил итә:

- шәхескә караган универсаль уку гамәлләре (үзбилгеләнеш, белем алуга әзерлек, белем дәрәҗәсен, танып белү эшчәнлегенә сәләтлелек, әхлакый-этик сыйфатларның камилләшүенә юнәлдерелгән гамәлләр);

- танып-белү универсаль уку гамәлләре (гомумуку, логик, проблема кую һәм аны хәл итү гамәлләре);
- коммуникатив универсаль уку гамәлләре — үзара мөнәсәбәтләрне җайлау һәм уртак нәтиҗәгә ирешү максатында ике яки берничә укучының үзара хезмәттәшлек итүенә корылган эш төрләре:
  — башкаларны тыңлый һәм ишетә белү;
  — аралашу бурычлары һәм шартларына туры китереп фикерне белдерә алу;
  — башкаларның фикере белән кызыксыну һәм үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү;
  — үз фикереңне дәлилле белү, тормыштан мисаллар китерү;
  — укылган текстлар буенча сораулар бирә алу;
  — бирелгән текстларның дәвамын сөйли алу, автор фикере белән чагыштыру;
  — сыйныфташлар каршында төрле темаларга, башкарылган проектлар буенча чыгыш ясау;
  — диалог төзүдә һәм коллектив фикер алышуда катнашу;
  — телнең грамматик һәм стилистик нормаларына нигезләнеп, монологик һәм диалогик сөйләм төзү күнекмәләренә ия булу;
  — төрле җавапларны тыңлау, чагыштыру, нәтиҗә ясау;
  — төрле карашларны тыңларга әзер булу һәм күмәк эш вакытында уртак фикергә килү;
  — гомуми эшне оештыруда инициатива күрсәтү (эшлекле лидерлык);
  — сораулар ярдәмендә мәгълүматны таба алу;
  — әңгәмәдәшнең үз-үзен тотышы белән идарә итү — аның гамәлләрен күзәтү, төзәтү һәм бәяләү, ышандыра алу;
  — эшлекле мөнәсбәтләр урнаштыру, нәтиҗәле хезмәттәшлек итү;
  — төркемдә конфликтсыз эшләүне тәэмин итү, үзара ярдәмләшү;
  — әңгәмәдәшләргә хөрмәтле караш булу.
- Регулятив универсаль уку гамәлләре (уку мәсьәләсен кую, планлаштыру, фаразлау, контроль, коррекция, бәяләү, үзрегуляция).

Дәрестә әлеге универсаль уку гамәлләренең дүрт төре дә, һичшиксез, тигез дәрәҗәдә формалаштырылырга тиеш.

Предмет нәтиҗәләренә таләпләр:

— сөйләм эшчәнлеге төрләре камилләшү;

— татар теленең коммуникатив, эстетик мөмкинлекләреннән оста файдалану;
— тел турында фәнни белемнәргә ия булу һәм аларны системалаштыру; тел бүлекләре һәм берәмлекләре арасындагы бәйләнешләрне аңлау; линвистиканың төп төшенчәләрен, телнең төп берәмлекләрен һәм грамматик категорияләрен үзләштерү;
— сүзне төрле яклап анализлау, сүзтезмәләргә һәм җөмләләргә синтаксик анализ ясау, шулай ук текстка күп аспектлы анализ ясау күнекмәләре формалашу.

Актив аралашуга корылган күнегүләр аша телнең грамматик нормаларын үзләштерү, лексикасын өйрәнү һәм актив сөйләмдә грамоталы итеп куллану тормышка ашырыла. Бу дәресләрнең эчтәлегендә текстны уку, текст буенча эшләү буенча күнегүләр системасы өстенлек итә: текст буенча сорауларга җавап бирү, эчтәлеген сөйләү, ахырын уйлап язу; темасын, микротемаларын билгеләү; планын төзү, конспектлау, аннотация язу, анализлау. Тексттан соңгы этапта текст буенча диалогик, монологик сөйләмгә чыгу оештырыла: телдән һәм язма, монологик (хикәяләү, тасвирлау, фикерләү) һәм диалогик сөйләм төзү эшчәнлеге башкарыла. Коммуникатив ысул лексик берәмлекләрне һәм аларның грамматик формаларын билгеле бер ситуацияләргә бәйләп өйрәтүне таләп итә. Чынбарлыкта кешеләр, аралашу сферасыннан чыгып, бер-берсе белән хәбәрләшәләр һәм моның өчен кирәкле тел берәмлекләреннән файдаланалар. Шуңа күрә рус балаларына татар телен чит тел буларак өйрәткәндә, аралашу ситуацияләренә бәйле репликаларны истә калдыру телне гамәли үзләштерүне җиңеләйтә һәм аның нәтиҗәлелеген арттыра. Шушы максаттан дәресләрдә алда әйтелгән бурычларны үтәүгә, ягъни татарча уку, язу, сөйләшү, тыңлап аңлауны камилләштерүгә юнәлдерелгән күнегүләр башкарыла: коммуникатив биремнәр, коммуникатив уеннар, ситуатив уеннар, рольле уеннар.

Яңа таләпләр укытучының позициясен үзгәртте: ул укучыларда фәнне өйрәнүгә уңай мотивация булдыра, аларның эшчәнлеген мөстәкыйль планлаштыруны оештыра, укучыларны куелган мәсьәләләрне мөстәкыйль чишү юлларын эзләүгә этәрә, иҗади сәләтләрен үстерү өчен уңай шартлар тудыра, белемнәрне үзләштерүгә иҗади якын килергә, мөстәкыйль фикерләргә өйрәтә, үзбәягә, үзконтрольгә өнди, укучыларның шәхси сәләтләрен, үзенчәлекләрен күреп, уңай бәяли, белем алуда яңа казанышларга рухландыра. Димәк, укытучы традицион рәвештә белем

бирүче генә түгел, ул — җитәкче, оештыручы, киңәшче, дус. Укучы исә дәрестә актив катнашучы: ул уку-танып белү эшчәнлегенә максат куя һәм аңа ирешергә тырыша, дәреснең эш планын төзүдә катнаша һәм нәтиҗәләрен бәяли, яңа белемнәрне укытучы җитәкчелегендә һәм мөстәкыйль үзләштерә, сораулар бирә, кызыксына, үз фикерен ачык белдерә. Болар барысы да укучыларның белем алуда шәхескә караган, метапредмет һәм предмет нәтиҗәләренә ирешүгә һәм универсаль уку гамәлләрен формалаштыруга хезмәт итә.

## УКУ ПРЕДМЕТЛАРЫННАН ЭШ ПРОГРАММАЛАРЫ ТӨЗҮ БУЕНЧА МЕТОДИК ТӘКЪДИМНӘР

Төп гомуми белем бирү программалары төп гомуми белем бирү оешмаларының локаль норматив акты булып тора, ә уку предметларының һәм дәрестән тыш эшчәнлек курсларының эш программалары бу локаль актларының структур компонентын тәшкил итә.

Эш программаларының *төп максаты* — укучылар тарафыннан төп гомуми белем бирү программасын үзләштерүдә планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешүне тәэмин итү. Эш программаларын төзүнең бурычлары — белем бирү оешмалары эшчәнлеге һәм укучылар контингентының үзенчәлекләреннән чыгып, аерым уку предметының эчтәлеген, күләмен, тәртибен билгеләү.Эш программаларының структурасы төп гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләрен истә тотып билгеләнә һәм Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән министрлыгының 2010 елның 17 декабреннән 1897 номерлы боерыгы нигезендә төп гомуми белем бирү федераль дәүләт белем бирү стандарталарына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 31 декабрендә чыккан 1577 номерлы боерыгындагы (Приказ Министерства образования и науки Российской Федерации от 31.12.2015 г. №1577 «О внесении изменений в федеральный государственный образовательный стандарт основного общего образования, утвержденный приказом Министерства образования и науки Российской Федерации от 17 декабря 2010 г. №1897» (Зарегистрировано в Минюсте России 02.02.2016 №40937) күрсәтмәләргә нигезләнә.

Уку предметларының, курсларының эш программаларының эчтәлеген тутырганда төп гомуми белем бирү Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләрен истә тотыла, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган уку предметлары буенча үрнәк программа материаллары, төп гомуми белем бирү оешмаларының төп белем бирү программаларының положениеләре һәм укыту планы, дәреслек кулланыла.

Эш программалары предмет укытучысы яки укытучылар төркеме тарафыннан бер уку елына төзелә һәм белем бирү учреждениесе тарафыннан 31 августтан да соңга калмыйча раслана. Алга таба мәктәп администрациясе эш программасына кертелгән положениеләрнең үтәлешен системалы рәвештә контрольдә тота.

Эш программаларын төзү, төзәтү, аларга үзгәрешләр кертү тәртибе локаль норматив акт билгели.

Алдагы таблицада төп гомуми белем бирү ФДББСның эш программалары структурасына куелган таләпләренә бәйле үзгәрешләр чагылдырыла.

| 2014 елның 29 декабрь РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы күрсәтмәләрендә эш программалары структурасына куелган таләпләр, ***гамәлдә түгел:*** | 2015 елның 31 декабрь РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы күрсәтмәләрендә эш программалары структурасына куелган таләпләр, ***гамәлдә:*** |
|---|---|
| Уку предметлары, курсларының эш программалары структурасы | |
| 1) уку предметын үзләштерүнең максаты конкретлаштырылган аңлатма язуы;<br>2) уку предметының гомуми характеристикасы;<br>3) уку планында уку предметының тоткан урыны;<br>4) уку предметын үзләштерүнең шәхескә караган, метапредмет һәм предмет нәтиҗәләре;<br>5) уку предметының эчтәлеге;<br>6) төп уку эшчәнлеген чагылдырган тематик планлаштыру<br>7) белем бирү процессының укыту-методик һәм материаль-техник яктан тәэмин ителеше;<br>8) уку предметын үзләштерүнең планлаштырган нәтиҗәләре. | 1) уку предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре;<br>2) уку предеметының эчтәлеге;<br>3) сәгатьләр санын күрсәткән тематик планлаштыру. |
| Дәрестән тыш эшчәнлек курсларының эш программалары структурасы | |
| Таләпләр куелмаган | 1) дәрестән тыш эшчәнлек курсын үзләштерү нәтиҗәләре;<br>2) дәрестән тыш эшчәнлекнең формаларын һәм төрләрен күрсәткән эчтәлек;<br>3) тематик планлаштыру. |

Эш программалары структурасына белем бирү учреждениесенең локаль норматив акты нигезендә өстәмә бүлекләр кертелергә мөмкин: уку предметы буенча календарь-тематик планлаштыру, бәяләү материаллары.

# ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕКНЕ ОЕШТЫРУ БУЕНЧА МЕТОДИК ТӘКЪДИМНӘР

ФДББС мәктәптә белем бирү процессына, шул исәптән дәрестән тыш эшчәнлекне оештыруга да яңа таләпләр куя. Федераль дәүләт стандартлары шартларында белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программасы дәрестә укыту эшчәнлеге һәм дәрестән тыш эшчәнлек аша дәүләт санитар-эпидимиологик кагыйдәләрне һәм нормативларны үтәп тормышка ашырыла (СанПиН 2.4.2.2821-10, 2015 елның 24 ноябрь редакциясендә).

Төп гомуми белем бирүнең ФДББС шартларында дәрестән тыш эшчәнлек түбәндәге норматив документлар һәм материалларга нигезләнеп оештырыла:

— Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының «Гомуми белем бирү федераль дәүләт белем бирү стандартларын керткәндә дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру турында» хаты, 12 май 2011 ел, №03-296;
— СанПиН 2.4.2.2821-10 «Гомуми белем бирү оешмаларында укыту шартларына һәм укытуны оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр»;
— СанПиН 2.4.4.1251-03 «Балаларга өстәмә белем бирү оешмаларына санитар-эпидемиологик таләпләр»;
— Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының «Гомуми белем бирү оешмаларында тәрбия бирү компонентын үстерү Программасының юнәлеше турында» хаты, 13 май 2013 ел, № ИР-352/09;
— Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының «Гомуми белем бирү оешмаларында тәрбия бирү компонентын үстерү Программасын тормышка ашыруда чаралар исемлеген формалаштыру буенча тәкъдимнәр турында» хаты, 12 июль 2013 ел, № 09-879;
— Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының «Дәрестән тыш эшчәнлек һәм өстәмә гомуми белем бирү программасын тормышка ашыру турында» хаты, 14 декабрь 2015 ел, № 09-3564.

Дәрестән тыш эшчәнлек — дәрестә уку эшчәнлегеннән кала укучыларны тәрбияләү максатына юнәлдерелгән барлык эш төрләре.

Укучыларның дәрестән тыш эшчәнлеген оештыруга ФДББС түбәндәге таләпләрне куя:

— дәрестән тыш эшчәнлек мәктәптә төп белем бирү программасының аерылгысыз өлеше;
— мәктәпнең төп белем бирү программасы составына кертелә;
— ФДББС таләпләрен тулысынча тормышка ашыруга ярдәм итә;
— программаның әлеге өлешенә караган эчтәлекне тутыру белем бирү учреждениесенең үз компетенциясендә;
— төп белем бирү стандартларын тормышка ашыру юлында белем бирү процессын оештыру формаларын сайлауны, дәрес һәм дәрестән тыш эшчәнлекне чиратлаштыруны белем бирү оешмасы үзе билгели;
— дәрестән тыш эшләр өчен сәгатьләр билгеләү укучылар теләгеннән (мөмкинлегеннән) чыгып эшләнелә.

Төп гомуми белем бирүнең ФДББС һәр гомуми белем бирү баскычында дәрестән тыш эшчәнлеккә тиешле гомуми сәгатьләр санын төгәл куя: төп гомуми белем бирү баскычында — 1750 сәгатькә кадәр, урта гомуми белем бирү баскычында — 700 сәгатькә кадәр. Мәктәп, үзенең төп белем бирү программасының эчтәлеге һәм оештыру үзенчәлегеннән чыгып, дәрестән тыш эшләргә сәгатьләр санын үзе билгели ала. Ләкин СанПиН 2.4.2.2821-10 укучыларның максималь атналык белем алу күләменә гигиеник таләпләрне төгәл куя (п. 10.5): мәсәлән, 5–9 нчы сыйныфларда, уку атнасының озынлыгы күпме булуга карамастан, атналык дәрестән тыш эшләр күләме 10 сәгатьтән артмаска тиеш. Шулай ук ДТЭ сәгатьләренең уку атнасында да, бәйрәм һәм ял көннәрендә дә, каникул вакытында да иҗтимагый файдалы эшләр башкару, тикшеренү эшчәнлеген алып бару, экскурсияләр, походлар, ярышлар үткәрү, театрларга, музейларга бару һәм башка чаралар өчен куллану мөмкинлеге ассызыклана.

Мәктәптә дәрестән тыш эшчәнлекне оештыруның төп максаты — укучыларның кызыксынуларын, сәләтләрен һәм ихтыяҗларын канәгатьләндерелек шартлар тудыру һәм аларның буш вакытларын дөрес оештыру, шуның нигезендә тәрбияләү һәм социальләштерү максатына ирешү.

Дәрестән тыш эшчәнлекнең юнәлешләре, төрләре һәм формалары:

| Төп юнәлешләр | Эш төрләре | Эш формалары |
|---|---|---|
| Гомуми интеллектуаль | Уен | Түгәрәкләр |
| Гомуми мәдәни | Танып-белү | Нәфис студияләр |
| Рухи-әхлакый | Рухи кыйммәткә | Спорт клублары һәм секцияләре |
| Спорт-сәламәтлекне | юнәлдерелгән | Яшүсмерләр оешмалары |
| саклау | проблемалы аралашу | Төбәкне өйрәнү эше |
| Нәфис-эстетик | Сәнгати иҗат | Фәнни-гамәли конференцияләр |
| Хәрби-патриотик | Техник иҗат | Олимпиадалар |

| | | |
|---|---|---|
| Иҗтимагый-файдалы эшчәнлек | Хезмәт<br>Спорт-сәламәтләндерү эшчәнлеге<br>Туризм, төбәкне өйрәнү эшчәнлеге | Ярышлар<br>Эзләнү һәм фәнни тикшеренүләр<br>Иҗтимагый-файдалы гамәлләр<br>Хәрби-патриотик оешмалар |

ДТЭнең гомуми системасында мөһим урынны тел һәм әдәбият укытучыларының эшчәнлеге алып тора. Бу эшчәнлек укытучыга предмет буенча белемнәрне ныгытырга, предметка карата кызыксыну уятырга, укучыларның иҗади сәләтләрен үстерергә ярдәм итә, мөстәкыйль фәнни-тикшеренү эшчәнлегенә әзерли, укучыларның мәдәни дәрәҗәсен арттыра, эстетик зәвык барлыкка китерә.

Дәрестән тыш эшләр төрле формаларда була. Кайберләре уку елы буена, хәтта берничә ел системалы рәвештә оештырыла: түгәрәкләр, клублар, студияләр. Эпизодик рәвештә уздырыла торган формалар да бар: олимпиада, әдәбият, китап атналыгы, декада һәм айлык, төрле кичәләр һәм иртәләр, радио тапшырулар, экспедиция һәм экскурсияләр, күргәзмәләр оештыру. Аерым эш формалары язма рәвештә башкарылалар: стена газетасы, бюллетень чыгару, кулъязма альбом яки журнал хәзерләү.

Дәрестән тыш эшләрдә катнашуның төп мотивы — кызыксыну. Ләкин кайсы формасы гына оештырылмасын, максат-бурычлар, эшнең эчтәлеге, оештырылу үзенчәлеге алдан билгеләнеп, катнашучыларга аңлатылырга тиеш.

Дәрестән тыш эшләрне уздырганда түбәндәге таләпләрне истә тотарга кирәк:

— дәрестән тыш эшләрдә укучының үз иреге белән катнашуы;
— укучыларны яхшы яки начарларга бүлүдән нык саклану, укучыны, ничек укуына һәм нинди булуына карамастан, дәрестән тыш эшләргә җәлеп итү;
— дәрестән тыш эшләрне әдәбият, тел, рус теле һәм әдәбияты, тарих, сынлы сәнгать, музыка һәм башка предмет дәресләре белән тыгыз бәйләнештә алып бару;
— дәрестән тыш эшләр формасының һәм методикасының мавыктыргыч булуы;
— сайланган эш төрләре, аларның максатлары һәм материаллары укучыларның яшь үзенчәлекләренә яраклы булып, әдәби хәзерлек дәрәҗәләрен истә тотып оештыру;
— дәрестән тыш эшләрне дәресләр белән тыгыз бәйләнештә алып бару, ләкин алар укучыларның мөстәкыйльлеге, иҗади

активлыгы, материаллар күплеге белән аерылып торырга, бизәкле һәм эмоциональ рәвештә, зур җанлылык белән үткәрелергә тиеш.

**Дәрестән тыш эшчәнлекне оештыруда төп принциплар һәм модельләр**

Дәрестән тыш эшчәнлек педагогика балаларның потенциаль мөмкинлекләрен һәм кызыксынуларын белергә ярдәм итә. Дәрестән тыш эшчәнлек — укучылар коллективын һәм укучыларның үзидарә органнарын булдыру максаты белән укучылар һәм сыйныф җитәкчесе арасында шәхесара мөнәсәбәтләр урнаштыру өчен бик әйбәт мөмкинлек ул.

Күпланлы дәрестән тыш эшчәнлек процессы укучыларның гомуммәдәни мәнфәгатьләренең үсешен тәэмин итәргә, әхлак тәрбия бирү бурычларын хәл итәргә булышырга мөмкин.

Дәрестән тыш эшчәнлек балаларга өстәмә белем бирү белән бәйләнгән, бу вакытта балаларның сәләтләрен үстерү өчен шартлар булдыру һәм аларны сәнгать, техник, экологик-биологик, спорт һәм башка эшчәнлеккә тарту эше турында сүз бара.

Факультативлар, мәктәпнең фәнни оешмалары эшчәнлеге, сайлап алу буенча уку курслары дәрестән тыш эшчәнлек белән балаларның өстәмә белем алулары арасында бәйләп торучы чылбыр булып тора.

Дәрестән тыш эшчәнлекне **гомуми принциплар** рәте нигезендә төзү үзен аклый.

**Гуманизация һәм гуманитаризация принцибы** укучыларны кыйммәтләр системасында дөрес ориентлаша белергә һәм төрле мәдәниятләр диалогына керергә ярдәм итә.

**Эчке һәм тышкы дифференциация принцибы —** укучыларның иҗади эшчәнлекнең төрле юнәлешләрендә эшләү мөмкинлекләрен һәм сәләтләрен билгеләү һәм үстерү, үзенә якын булган дисциплиналар сайлау мөмкинлеген һәм аларга һәрбер конкрет предметны үзләштерүнең төрле тирәнлегендә эшләп карау мөмкинлеген булдыру ул.

**Сайлау иреге принцибы —** укучыларның үзләренә дәрестән тыш эшчәнлекнең формаларын һәм төрләрен мөстәкыйль рәвештә сайлап алу мөмкинлеген тәкъдим итү, үзенең нәтиҗәләре өчен җаваплылык хисе тәрбияләү.

**Ирекле үзбилгеләнү һәм үзреализацияләнү мөмкинлеге.**

Баланың **шәхси мәнфәгатьләренә, ихтыяҗларына, сәләтенә йөз тоту.**

**Бердәмлек принцибы —** укыту, тәрбия бирү, үсеш бердәмлеге.

**Экологизация принцибы —** балада әйләнә-тирә дөнья өчен җаваплылык хисе үстерү.

Белем бирү процессының **гамәли-эшчәнлекле нигезе. Дәрестән тыш эшчәнлек нәтиҗәләре.**

Укучыларның дәрестән тыш эшчәнлекнең тәрбияви нәтиҗәләре өч дәрәҗә буенча бүленә.

*Нәтиҗәләрнең беренче дәрәҗәсе* — укучыларның социаль белем алулары (иҗтимагый нормалар, җәмгыятьнең төзелеше, җәмгыятьтә социаль яктан кабул ителә һәм кабул ителми торган үз-үзеңне тоту формалары һ.б.), социаль чынбарлыкны һәм көндәлек тормышны аңлау.

Нәтиҗәләрнең әлеге дәрәҗәсенә ирешү өчен укучының (аның өчен мөһим булган) уңай социаль белем һәм көндәлек тәҗрибә чыганагы булган шәхесләр — укытучылары белән үзара бәйләнеше зур әһәмияткә ия (нигездә, өстәмә белем бирүдә).

*Нәтиҗәләрнең икенче дәрәҗәсе* — укучының җәмгыятьнең база кыйммәтләренә карата булган борчылуларын һәм позитив мөнәсәбәтләрен (кеше, гаилә, Ватан, табигать, дөнья, белем, хезмәт, мәдәният) алуы.

Нәтиҗәләрнең әлеге дәрәҗәсенә ирешү өчен укучыларның сыйныф, мәктәп дәрәҗәсендә, ягъни дустанә просоциаль тирәлектә аралашулары зур әһәмияткә ия. Нәкъ менә шундый социаль тирәлектә бала үзендә булдырылган социаль белемнәрен практик яктан раслый, аларның кадерен белә башлый.

*Нәтиҗәләрнең өченче дәрәҗәсе* — укучының мөстәкыйль рәвештә башкарган иҗтимагый гамәлләр тәҗрибәсен алуы. Бары тик мөстәкыйль рәвештә башкарган иҗтимагый гамәлләр вакытында гына, ачык социумдагы эшчәнлегендә, мәктәпнең дустанә тирәлегеннән читтә генә яшь кеше, чынлыкта, социаль хезмәткәр, гражданин, ирекле кеше була ала. Нәкъ менә шундый мөстәкыйль рәвештә башкарган иҗтимагый гамәлләр нигезендә генә алардан башка гражданинның һәм гражданлык җәмгыятенең яшәешен күз алдына китереп булмаган батырлык, лаеклы эш-гамәлләргә әзер булу кебек тормышта бик кирәкле тәҗрибә алып була.

Дәрестән тыш эшчәнлек нәтиҗәләренең өч дәрәҗәсенә дә ирешү балаларда тәрбия һәм социальләшү эффектлары барлыкка килү мөмкинлеген арттыра.

Кече яшьтәге мәктәп укучыларының дәрестән тыш эшчәнлеген оештырганда, 1 нче сыйныфка кергән балалар яңа социаль белемгә тартылучан, үзләре өчен яңа булган мәктәп чынбарлыгын аңларга омтылучан

булуларын исәпкә алырга кирәк. Педагог бу тенденцияне хупларга, дәрестән тыш эшчәнлекнең кулланыла торган формалары ярдәмендә баланың *беренче дәрәҗә нәтиҗәләренә* ирешүен тәэмин итәргә тиеш.

2, 3, 4, 5 нче сыйныфларда, кагыйдә буларак, балалар коллективының үсеш процессы көч ала, кече яшьтәге мәктәп укучыларының шәхесара мөнәсәбәтләре кискен активлаша, бу исә дәрестән тыш эшчәнлек нәтиҗәләрнең икенче дәрәҗәсенә ирешү өчен бик уңышлы ситуация тудыра.

Мәктәптә өч ел уку дәвамында беренче дәрәҗә нәтиҗәләреннән эзлекле рәвештә икенче дәрәҗә нәтиҗәләренә күчү кече яшьтәге мәктәп укучыларының 4, 5 нче сыйныфта исә иҗтимагый эш, гамәлләр пространствосына чыгу мөмкинлеген арттыра (ягъни нәтиҗәләрнең өченче дәрәҗәсенә ирешү). Мондый күчеш башлангыч һәм 5нче сыйныф укучысы өчен дустанә тирәлеккә чыгу буларак билгеләнергә тиеш. Хәзерге заман социаль ситуациясенә хас булган конфликтлылык һәм билгесезлекнең билгеле бер дәрәҗәдә чикле булуы мөһим.

Дәрестән тыш эшчәнлек укучыларның шәхси ихтыяҗларын тәэмин итә. Дәресләрдән соңгы мәктәп — бала өчен иҗат дөньясы, аның кызыксынуларын, мавыгуларын, үз-үзен ачуы ул. Биредә бала сайлау хокукына ия, үз ихтыярын эшкә җигә ала, шәхес буларак ачыла. Мәктәп аның өчен икенче өе булып, дәрестән тыш эшчәнлекне тәрбия һәм белем бирүнең тулы бер пространствосына әйләндерү өчен баланы дәресләрдән соң төрле шөгыльләр белән кызыксындыру мөһим. Дәресләрдән тыш эшчәнлек вакытында мавыгучан балалар белән педагогның үзенчәлекле эмоциональ тирәлеге хасил була, биредә спорт, сәнгать фән, техника һәм башка төр эшчәнлектә уңышка омтылган укучыларның белем алулары тормышка ашырыла.

Федераль дәүләт белем бирү стандартларында күрсәтелгәнчә, дәрестән тыш эшчәнлек белем бирү һәм тәрбия процессының аерылгысыз бер өлеше һәм укучыларның буш вакытларын оештыруның бер формасы булып тора. Бүгенге көндә дәрестән соң эшчәнлек дәрестән соңгы вакытта укучыларның ихтыяҗларын канәгатьләндереп оештырыла торган эшчәнлек итеп күзаллана.

Дөрес оештырылган дәрестән тыш эшчәнлек системасы укучының конкурентлылыкка сәләтлелегендә чагылачак өлкә булып тора. Мәктәп һәм өстәмә белем бирү оешмалары белем бирүнең вариативлылыгын, сайлау мөмкинлеген тәэмин итәләр:

- дәрестән тыш эшчәнлек — төп белем бирүнең яңа төр уку эшчәнлеген үзләштерүдә педагогка һәм укучыга ярдәм итүгә юнәлгән, уку мотивациясен үзгәртүгә сәләтле өлеше;

• ул белем бирү пространствосын киңәйтергә ярдәм итә, укучыларның үсеше өчен өстәмә шартлар тудыра;

• дәрестән тыш эшчәнлек белем бирүнең бөтен периодларында җайлашу, ияләшү этапларында балаларга ярдәм итүне тәэмин итә торган эшчәнлек булырга тиеш.

Ә бу исә билгеләнгән белем бирү нәтиҗәсенә чыгу — база белемнәрен уку процессыннан тыш башка ситуацияләрдә кулланырга әзер булу. Гомумән, бу исә төрле балалар өчен уңыш ситуациясе дә, социальләшүне тәэмин итү дә булып тора.

Дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру принциплары:

• укучыларның яшь үзенчәлекләренә туры килү;

• уку эшчәнлеге технологияләре белән дәвамчанлык (бәйләнеш) булдыру;

• дәрестән тыш эшчәнлек үткәрүнең традицияләренә һәм уңышлы тәҗрибәсенә таяну;

• мәктәпнең тәрбия бирү системасы кыйммәтләренә таяну;

• шәхси кызыксынулары һәм сәләтләре нигезендә баланың ирекле сайлап алуы.

Ләкин, беренче чиратта, дәрестән тыш эшчәнлек — **шәхескә караган һәм метапредмет нәтиҗәләре** ул. Бу исә әлеге процесста дәрестән тыш эшчәнлекнең үзенчәлеген дә билгели.

Дәрестән тыш эшчәнлекне оештыруның моделен түбәндәге алгоритм буенча гамәлгә ашырырга мөмкин:

I этап — дәрестән тыш эшчәнлекнең максатларын, принципларын, аларның төп белем бирү программаларында чагылыш табуларын билгеләү;

II этап — белем бирү оешмалары тарафыннан дәрестән тыш эшчәнлекнең тәкъдим ителгән модельләренә анализ ясау;

III этап — дәрестән тыш эшчәнлекнең төрле модельләрен ресурслары ягыннан тәэмин ителешенә анализ ясау;

IV этап — дәрестән тыш эшчәнлекне оештыруның моделен сайлау, максатлар, принциплары, аның тормышка ашырылу мөмкинлекләре белән ярашлы хәлдә аның эчтәлек ягыннан тулыландырылуы, тавсирламасы.

Дәрестән тыш эшчәнлекне алгоритм нигезендә оештыру Федераль дәүләт белем бирү стандартларында гамәлгә кертүне тәэмин итүдә уңышлы юл булып тора.

Белем бирү учреждениеләренең дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру **модельләренең** берничә классификациясе бар.

**Мәктәп эчендәге модель** учреждениенең дәрестән тыш эшчәнлекне үткәрергә тиешле ресурслар комплексы булганда тормышка ашырыла.

**Тышкы модель** учреждениеның дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру өчен үз ресурслары булмаганда тормышка ашырыла. Дәрестән тыш эшчәнлек программасын тормышка ашыру бер яки берничә учреждение — социаль партнёрлар арасында булырга мөмкин.

**Катнаш модель** иң еш кулланыла торган модель, бер яктан, күп кенә оешмалар дәрестән тыш эшчәнлекне оештыруда ресурсларга кытлык кичерәләр, икенче яктан, өстәмә белем бирү оешмалары белән булган мөнәсәбәтләрне сакларга һәм үстерергә тырышалар.

**Өстәмә белем бирү моделе** (өстәмә белем бирүнең институциональ нигезендә) факультативлар, мәктәпнең фәнни оешмалары, һөнәри юнәлгән оешмалар, сайлап алу буенча курслар кебек формалар бәйләп торучы чылбыр булып торалар. Эшчәнлеккә өстәмә белем бирү белгечләрен тарту, шулай ук белем бирү процессын практик-юнәлгәнлек һәм эшчәнлекле нигездә оештыру әлеге модельнең өстенлеге булып тора.

**«Тулы көн мәктәбе» моделе.** «Тулы көн мәктәбе» моделенең нигезе булып дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру озайтылган көн төркеме җитәкчеләре тарафыннан үткәрелүе тора. Әлеге модельне нәрсәләр характерлап торучы сыйфатлар: баланың белем бирү учреждениесендә көн буе булуына яхшы шартлар тудыру; белем бирү учреждениесының тәрбия бирү һәм төп белем бирү программасы кысаларында белем бирү, тәрбия бирү һәм үстерү процессларының эчтәлек ягыннан берлеге; санитар-эпидемиологик кагыйдәләрне һәм нормаларны үтәүне тәэмин итә торган сәламәтлекне саклау тирәлеге булдыру; балаларның үзреальләшүләрен булдыру өчен шартлар тудыру; төп һәм өстәмә белем бирү программаларының интеграциясенә таяну.

Көне буена сузылган белем бирү процессын уңышлы тормышка ашыру өчен шартлар комплексын (өстәмә белем бирүне дә, сәламәтлекне саклау шартларын да кертеп) булдыру әлеге модельнең өстенлеге булып тора.

**Инновация-белем бирү моделе.** Инновация-белем бирү моделе белем бирү учреждениесендә булган федераль, региональ, муниципаль яки институциональ дәрәҗәдәге мәйданчыкларга таяна.

Инновация-белем бирү моделе гомуми белем бирү учреждениеләренең өстәмә һөнәри педагогик белем бирү учреждениеләре, югары һөнәри белем бирү учреждениеләре, фәнни оешмалар, муниципаль методик хезмәт белән тыгыз мөнәсәбәттә эшли.

Дәрестән тыш эшчәнлек — ул төп гомуми белем бирүгә ниндидер механик өстәлмә генә булмыйча, сәләтле балалар яки өлгермәүчеләр белән эш оештыруга гына кайтып калмыйча, һәрбер баланың сәләтен, кызыксынуларын ача торган иҗат дөньясы булуын истә тотарга кирәк.

## ТӘКЪДИМ ИТЕЛГӘН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. 2016/2017нче уку елында Татарстан Республикасында рус телендә гомуми белем бирү мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбиятын укыту үзенчәлекләре. Дәресләрнең технологик карталары / Төзүчеләр: Шәмсетдинова Р.Р., Мөхәрләмова Г.Н., Фәттахова Р.Ф., Һадиева Г.В. — Казан: ТРМҮИ, 2016. — 69 б.

2. 2016/2017нче уку елында Татарстан Республикасында татар телендә гомуми белем бирү мәктәпләрендә татар телен укыту үзенчәлекләре. Дәресләрнең технологик карталары / Төзүчеләр: Шәмсетдинова Р.Р., Мөхәрләмова Г.Н., Фәттахова Р.Ф., Һадиева Г.В. — Казан: ТРМҮИ, 2016. — 36 б.

3. IX сыйныф укучыларын татар теленнән Бердәм республика тестын үтүгә әзерләү (текст белән эшләү методикасы)/авт.-төз.: Гыйләҗева Л.Г., Һадиева Г.В. — Казан: ТРМҮИ, 2016. — 34 б.

4. Гильманов Д.Ш. Уроки татарского языка на основе предметных действий: для русскоязычных детей дошкольного и младшего школьного возраста. — Казань: ГАОУ ДПО ИРО РТ, 2016. — 75 с.

5. Заманча технологияләргә нигезләнгән татар теле һәм әдәбияты дәресләре (ТР Лаеш муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучыларының эш тәҗрибәсеннән)/ Төзүчеләр: Шәмсетдинова Р.Р., Мөхәрләмова Г.Н., Һадиева Г.В. — Казан: ТРМҮИ, 2016. — 88 б.

6. Изложение язуга әзерлек: татар теле һәм әдәбияты буенча башлангыч гомуми һәм төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә куючы педагогик хезмәткәрләр өчен методик ярдәмлек / авт.-төз. М.Г. Мозаффарова. — Казан: ТРМҮИ. — 35 б.

7. Карпухина Н.И. Сборник контрольных работ (по УМК «Сәлам»). — Казан, ТРМҮИ, 2017. — 52 б.

8. Мозаффарова М.Г. Тәгълим-тәрбия процессын оештыруда милли мәгърифәтчелек идеяләрен гамәлгә кую: гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре өчен тәкъдимнәр. — Казан: ТРМҮИ, 2016. — 56 б.

9. Мухарлямова Г.Н, Гилязова Л.Г., Валиева М.Н. и др. Методические рекомендации по составлению рабочих программ для 7 классов общеобразовательных организаций (с обучением на татарском языке). — Казан, ТРМҮИ, 2017. — 39 б.

10. Мухарлямова Г.Н, Хадиева Г.В., Ханнанова М.Х. и др. Методические рекомендации по составлению рабочих программ для 7 классов общеобразовательных организаций (с обучением на русском языке для изучающих татарский язык как родной). — Казан, ТРМҮИ, 2017. — 67 б.

11. Мухарлямова Г.Н., Фаттахова Р.Ф., Сиразетдинова З.П. и др. Методические рекомендации по составлению рабочих программ для 7 классов общеобразовательных организаций (с обучением на русском языке). — Казан, ТРМҮИ, 2017. — 44 б.

12. Рабочие программы по татарскому языку для образовательных организаций СПО (4 наименований). — Казан, ТРМҮИ, 2017. — 20 с.; 18 с.; 15 с.; 20 с.
13. Рус телендә сөйләшүче укучыларга татар теле буенча олимпиадага әзерләнү өчен биремнәр / Төзүче: Р.Р. Шәмсетдинова. — Казан, 2016. — 17 б.
14. Татар теле дәреслекләренә электрон кушымталар. Методик ярдәмлек / Төзүчеләр: Р.Р. Шәмсетдинова, А.А. Башарова. — Казан: ТРМҮИ, 2015. — 68 б.
15. Татар телен өйрәнү өчен укучыларны төркемнәргә бүлү буенча тәкъдимнәр: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларының I сыйныфлары өчен. Татар телен һәм әдәбиятын укытуда уен технологияләре (ТР гомуми белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучыларының эш тәҗрибәсеннән) / Төзүчеләр: Шәмсетдинова Р.Р., Фәттахова Р.Ф., Мөхәрләмова Г.Н., Һадиева Г.В. — Казан: ТРМҮИ, 2016. — 23 б.
16. Татар телен һәм әдәбиятын заман таләпләре буенча укытабыз (ТР Бөгелмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучыларының тәҗрибәсеннән. /Төзүчеләр: Шәмсетдинова Р.Р., Мөхәрләмова Г.Н., Һадиева Г.В., Мәхмүтова Ф.Т. — Казан: ТРМҮИ, 2015. — 160 б.
17. Татар телен һәм әдәбиятын укытуда коммуникатив технологияләр (ТР гомуми белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучыларының эш тәҗрибәсеннән) / Төзүчеләр: Шәмсетдинова Р.Р., Фәттахова Р.Ф., Мөхәрләмова Г.Н., Һадиева Г.В. — Казан: ТРМҮИ, 2016. — 53 б.
18. Татар телен һәм әдәбиятын укытуда уен технологияләре (ТР гомуми белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучыларының эш тәҗрибәсеннән) / Төзүчеләр: Шәмсетдинова Р.Р., Фәттахова Р.Ф., Мөхәрләмова Г.Н., Фәттахова Р.Ф., Һадиева Г.В. — Казан: ТРМҮИ, 2016. — 55 б.
19. Фаттахова Р.Ф. Практический татарский язык: методическое пособие для изучающих татарский язык. — Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. — 176 с.
20. Шамсутдинова Р.Р. Методические рекомендации по подготовке к олимпиадам по татарскому языку русскоязычных учащихся. — ТРМҮИ, 2016. — 36 б.
21. Шамсутдинова Р.Р., Зиннатуллин Р.К., Фаттахова Р.Ф., Гилязова Л.Г., Хадиева Г.В. Современные технологии в обучении татарскому языку и литературе. — Казан, ТРМҮИ, 2017. — 94 б.
22. Шамсутдинова Р.Р., Фаттахова Р.Ф. Методические рекомендации по преподаванию предметов «Татарский язык и литература». — Казан, ТРМҮИ, 2017. — 39 б.
23. Шамсутдинова Р.Р., Фаттахова Р.Ф., Гилязова Л.Г., Хадиева Г.В. Сборник текстов и заданий для проведения контрольных работ по татарскому языку. Казан, ТРМҮИ, 2017. — 28 б.

24. Шамсутдинова Р.Р., Фаттахова Р.Ф., Гилязова Л.Г., Хадиева Г.В. Сборник заданий школьного, муниципального и республиканского туров олимпиад по татарскому языку для русскоязычных обучающихся. Казан, ТРМҮИ, 2017. — 33 б.

25. Шамсутдинова Р.Р., Фаттахова Р.Ф., Гилязова Л.Г., Хадиева Г.В. Сборник татарских версий КИМ и тренировочных заданий ОГЭ по предметам.

26. Шамсутдинова Р.Р., Фаттахова Р.Ф., Гилязова Л.Г., Хадиева Г.В. Сборник КИМ для мониторинга знаний обучающихся русскоязычных групп 4, 6, 8 классов по татарскому языку. Казан, ТРМҮИ, 2017. — 39 б.

27. Эш программаларын төзү буенча методик тәкъдимнәр (5 нче сыйныф өчен «Татар әдәбияты» предметы буенча эш программасы). — Казан: Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, 2015. — 94 б.

28. Эш программаларын төзү буенча методик тәкъдимнәр (5 нче сыйныф өчен «Татар теле» предметы буенча эш программасы). — Казан: Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, 2015. — 136 б.

29. Эш программаларын төзү буенча методик тәкъдимнәр (6 нчы сыйныф өчен «Татар теле», «Татар әдәбияты» буенча эш программалары). 1 кисәк. — Казан: Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, 2016. — 108 б.

30. Эш программаларын төзү буенча методик тәкъдимнәр (6 нчы сыйныф өчен «Татар теле», «Татар әдәбияты» буенча эш программалары). 2 кисәк. — Казан: Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, 2016. — 108 б.

**Интернет ресурслары**

http://минобрнауки.рф (РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы);
http://www.edu.ru («Российское образование» федераль порталы);
http://mon.tatarstan.ru (ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы);
http: //edu.tatar.ru
http://www.irort.ru (ТР Мәгарифне үстерү институты)
http://www.fasi.gov.ru Фән һәм инновацияләр буенча федераль агентлык
http://www.obrnadzor.gov.ru Рособрнадзор
http://www.apkppro.ru РФ мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм профессиональ әзерләү академиясе
http://www.lexed.ru Федеральный центр образовательного законодательства
http://www.rustest.ru Федераль тестүткәрү үзәге
http://www. tatedu.ru
http://www.edu. kzn.ru ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы Белем порталы
http://www.mon.tatar.ru ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы
http://www.it-n.ruhttp://. belem.ru
http://. tatcenter.ruТР мәгълүмати-аналитик порталы

http://. Tat. Tatar - inform.ru ТР мәгълүмат агентлыгы
http://. intertat.ru ТР электрон газетасы
http://. xat.ru Татар хат алышу хезмәте
http://. suzlek.ruon- lineрусча сүзлеге
http://. Kitapxane.at.ru татар телендәге әдәби әсәрләр китапханәсе
http://. Tatar.com.ru татар теле сүзлекләр һәм үзөйрәткечләр
http://. Tatarca.boom.ru татарча текстлар

2018/2019 НЧЕ УКУ ЕЛЫНДА
ТАТАР ТЕЛЕН ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫН
ЧИТ ӘДӘБИЯТ БУЛАРАК УКЫТУНЫҢ
АКТУАЛЬ ПРОБЛЕМАЛАРЫ

Форм.бум.60x84 1/16. Усл.п.л. 3 Гарнитура Times

Институт развития образования Республики Татарстан
420015 Казань, Б.Красная, 68
Тел.: (843)236-65-63 тел./факс (843)236-62-42
E-mail: irort2011@gmail.com